• ВӘГАЗЬ •
НИ ӨЧЕН ВАКЫТНЫҢ БӘРӘКӘТЕ БЕТТЕ?
6 бит

• ВАКЫЙГА •
"БИЛАЛ" МУЛЬТФИЛЬМЫ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ
8 бит

• ГЫЙБАДӘТ•
НИ ӨЧЕН НАМАЗ УКЫЙБЫЗ?
12 бит

• ӘДӘБИ СӘХИФӘ •
КОЯШЛЫ ДАЛА КЫЗЫ
14 бит

№ 12 (317) | Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы | рабигыль-ахыр – җөмәдәл-әүвәл, 1443

декабрь, 2021

# دين و معيشت

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ




*Ибраһим бине Әдһәм рахимәһуллаһи исемле галим янына бер кеше килә дә:*
*– Әй, Ибраһим хәзрәт, минем гөнаһ кыласы килә, гөнаһлар эшләргә миңа рөхсәт бир, – дип мөрәҗәгать итә...*

*Дәвамы 4 нче биттә*

Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръән аятьләре булганлыктан, басмага игътибарлы булыгыз!

12+

# 2022 ЕЛДА ДИНИ БӘЙРӘМНӘР ҺӘМ ИСТӘЛЕКЛЕ ЕЛЛАР

## Һиҗри исәп буенча 1443–1444 еллар

| | | |
|---|---|---|
| 4 гыйнвар | 1 җөмәдәл-ахыр | |
| 2 февраль | 1 раҗәб | |
| 3 февраль | 2 раҗәб | Рәгаиб кичәсе |
| 27 февраль | 26 раҗәб | Мигъраҗ кичәсе |
| 4 март | 1 шәгъбан | |
| 17 март | 14 шәгъбан | Бәраәт кичәсе |
| 2 апрель | 1 Рамазан | Рамазан ае башлана |
| 27 апрель | 26 Рамазан | Кадер кичәсе |
| 2 май | 1 шәүвәл | Ураза гаете |
| 31 май | 1 зөлкагъдә | |
| 30 июнь | 1 зөлхиҗҗә | |
| 8 июль | 9 зөлхиҗҗә | Гарәфә көне |
| 9 июль | 10 зөлхиҗҗә | Корбан бәйрәме |
| 8,9,10,11,12 июль | 9,10,11,12,13 зөлхиҗҗә | Тәкбир Әт-Тәшрик көннәре |
| 30 июль | 1 мөхәррам | Һиҗри буенча 1444 ел башлана |
| 8 август | 10 мөхәррам | Гашурә көне |
| 28 август | 1 сафәр | |
| 27 сентябрь | 1 рабигыль-әүвәл | |
| 7 октябрь | 11 рабигыль-әүвәл | Мәүлид Ән-Нәби |
| 27 октябрь | 1 рабигыль-ахыр | |
| 25 ноябрь | 1 җөмәдәл-әүвәл | |
| 24 декабрь | 1 җөмәдәл-ахыр | |

# 2021 елда «Хозур» да уникаль басмалар нәшер ителде

***2021 елда Нәзарәтнең «Хозур» нәшрият йорты 96 меңнән артык гомуми тираж белән 80 исемдәге китап нәшер итте.***

Нәшрият эшчәнлеге ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең традицион ислам кыйммәтләрен пропагандалау өлкәсендәге эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләреннән берсе булып тора һәм «Хозур» нәшрият йорты тарафыннан гамәлгә ашырыла. 2021 елда мөселманнар арасында дини гыйлем тарату, милли мәдәниятне, гореф-гадәтләрне һәм өммәтнең интеллектуаль мөмкинлекләрен үстерүнең мөһим факторы буларак, укуга кызыксынуны арттыру максатыннан, нәшрият тарафыннан 80 төрле китап дөнья күрде. Аларның гомуми тиражы 96510 данә тәшкил итә. Шунысы игътибарга лаек, аларның яртысыннан артыгы – яңадан нәшер ителгән бестселлерлар, алар мөселман укучылары арасында үз популярлыгын югалтмыйча, укучылар өчен һаман кызыклы булып кала бирә. Шулар арасына Камил хәзрәт Сәмигуллинның «Каждый может стать Коран-Хафизом», «Расскажи мне об исламе» һәм «Ислам турында сөйләшик», доктор Рамадан Әл-Бутиның «Понимание жизни Пророка с кратким очерком истории праведных халифов», нәсыйхәтләр белән «Рухуль бәйан» тәфсире, «Калям Шариф. Перевод смыслов», «Абу Ханифа – великий муджтахид», 2 томда «Тәлфикуль Әхбар», «Тәрбияле хатын» һәм башка китапларны кертергә мөмкин.

Шул ук вакытта 2021 елда ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты уникаль басмалар да нәшер итте. Мәсәлән, «Сахих Әл-Бохари» хәдисләр җыентыгының Әд-Дагыстани версиясенең рус теленә тәрҗемәсе, «Клад для маленьких мусульман», «Ислам дине: яшүсмерләр өчен», «Доводы против ваххабитов» китаплары.

«Сахих Әл-Бохари» – мөселманнар өчен әһәмияте буенча Коръәннән кала икенче урында тора һәм төп сөнни хәдисләр җыентыгының берсе булып санала. Кыскартылган вариантларның иң уңышлысы булып «Зөбдәтел-Бохари» санала, аны XIX гасырда яшәгән дагыстанлы мөселман галиме Гомәр Дияветдин Әд-Дагыстани төзегән. Моңа кадәр бу хезмәтнең рус теленә тәрҗемә ителгәне булмады, әмма Рәсәйдә исламга каршы килә торган идеяләрнең таралуы үзебезнең дини-илаһият фәне фикерләрен яңадан торгызу зарурлыгын тудырды. Гарәп теленнән рус теленә тәрҗемә ителеп дөнья күргән «Сахих Әл-Бохари» хәдисләр җыентыгының «Зөбдәтел-Бохари» версиясе ышанычлы хәдисләрне табып укуны җиңеләйтте һәм Рәсәй мөселманнары өчен хакыйкый сөнни традицияләрне якынайтты. Әлеге басма Дагыстан мөфтияте белән берлектә әзерләнде.

2021 елда «Хозур» нәшрият йорты китапларын электрон форматта сатуга чыгару зур яңалык булды. Укучыларга уңайлы булсын өчен, хәзер «Хозур» нәшрият йортының **www.huzurshop.ru** адресы буенча урнашкан рәсми интернет-кибетендә китапларның кәгазь вариантын гына түгел, электрон версиясен дә сатып алырга мөмкин. Моннан тыш, быел Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты китапларын илнең зур сәүдә онлайн-мәйданчыкларында сатып алырга да мөмкинлек туды. «Хозур» нәшриятында дөнья күргән мөселман әдәбиятын Wildberries, OZON, KazanExpress.ru аша, шулай ук «Читай-город», «ЛитРес» китап интернет-кибетләрендә сатып алырга мөмкин.

«Хозур» нәшрият йортында 8 ел эчендә гарәп, рус, татар һәм иске татар телләрендә барлыгы 700 мең данәдән артык дини, тарихи, фәнни әдәбият дөнья күрде. Һәр басма Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Эксперт советы тарафыннан мәҗбүри тикшерү аша уза.

■ **dumrt.ru** сайтыннан алынды

# Туган телләр елы кысаларында Диния нәзарәте эшчәнлеге

***2021 ел Татарстан Республикасында Президент Рөстәм Нургали улы Миңнеханов тарафыннан Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителгән иде. Бу вакыт эчендә Диния нәзарәте татар телен һәм татар милли үзенчәлекләрен саклап калуга юнәлтелгән 6 зур проектны тормышка ашырды, 9 фәнни җыен уздырды, дин кардәшләр һәм милләттәшләр арасында 8 төрле бәйге үткәрде. Моннан тыш та, мөфтиятнең мәдрәсәләрендә һәм мөхтәсибәтләрендә дә күпсанлы күркәм чаралар оештырылды. Шунысы да игътибарга лаек, Нәзарәт үзе дә 2021 елны Татарстанда Туган тел елы дип игълан иткән иде.***

Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында Диния нәзарәтенең иң мәртәбәле проектларына беренче онлайн-мәдрәсә, «Казан басма» татар милли компьютер шрифтын эшләү, Коръәннең яңа «Казан басмасын» әзерләү, 100 мәчеттә татар теле курсларын оештыру һәм татар батыры образын кайтару өчен «Туган батыр» персонажын эшләү һәм бөтен дөньяга танылган «Билал» мөселман мультфильмын татар теленә тәрҗемә итү керә.

Беренче татар онлайн-мәдрәсәсе 2021 елның беренче көннәрендә, гыйнвар аенда эшли башлады. 11 ай эчендә мәдрәсә сайтына 50 000 «шәкерт» кереп укыган. Шуларның 400е укуын башыннан алып ахырына кадәр тәмамлап, ислам нигезләрен үзләштерү турында махсус сертификатка ия булды. Әһәмияткә ия нәтиҗәләрнең тагын берсе – укучыларның яшь үзенчәлекләре: онлайн-мәдрәсәдә аларның 35% 44 яшькә кадәр булулары бик куанычлы. Татар дөньясында әлеге проектка ихтыяҗ зур булуны аның географиясе раслый: Рәсәй татарларыннан тыш, порталдан 300дән алып 1000 кешегә кадәр Казахстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Австралия, АКШтагы милләттәшләр дә файдаланган. Аурупа, Азия, Төньяк Американың башка илләреннән файдаланучылар саны – 100дән ким.

Нәзарәтнең тагын бер казанышы – «Казан басма» татар милли компьютер шрифтын эшләү. Шрифт чын тарихи типографик оттискысы нигезендә эшләнде һәм ул Коръәнне бастыруның борынгы татар традицияләрен кайтаруда зур этәргеч булачак, китап бастыру өчен яңа техник мөмкинлекләр бирәчәк.

Шрифт нигезендә Идел буе Болгар дәүләтендә исламны кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан Нәзарәт яңа Коръән басмасы әзерләде. Басма хәзерге халыкара стандартларга һәм М.Бигиевнең «Тасхих расм хат әл-Коръән» һәм Ш.Мәрҗанинең «Фаваид аль-Мухимма» китапларында бирелгән тәкъдимнәренә туры китерелгән.

Бу елда 100 мәчеттә татар теле курслары тәмамланды. Алты айга сузылган дәресләрдә 1500 укучы белем алды. Укытуның махсус методикасын РИИ эшләде, дәреслекне Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрияты бастырды. Норлат мөхтәсибәтендә татар телен укытуга балалар өчен логопед җәлеп ителде.

Халыкның төрле яшь төркемнәре арасында милли һәм дини үзаң, туган телгә мәхәббәт һәм кызыксыну тәрбияләү, татар телен өйрәнүдә теләкне арттыру өчен, Диния нәзарәте тарафыннан 8 иҗади бәйге дә үткәрелде. Болар: «Таян Аллага!», «Илаһи моң», «Милли моң» мөнәҗәтләр фестивале, татар мәкаме буенча Коръән уку бәйгесе, журналистлар өчен «Динем – ислам, милләтем – татар» бәйгесе, мәчетләр һәм имам-хатыйблар өчен «Изге әманәт» бәйгесе һәм татарлар арасында «Оста вәгазьче» бәйгесе. Татарстан шәкертләре арасында татар теле, әдәбияты һәм тарихы буенча республикакүләм олимпиада да оештырылды.

Моннан тыш, мөхтәсибәтләр тарафыннан туган телләрне саклау, татар рухи мирасын өйрәнүгә багышланган 9 фәнни җыен уздырылды. Якупов, Әтрәч, Мунчәли, Өркеш, Мәчкәрә, Иманколый, Толымбай укулары, Чаллыда «XIX гасыр азагы – XX гасыр башы татар дин галимнәре мирасы» фәнни-гамәли конференциясе һ.б.

Әлегә тәмамланмаган булса да, Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елында эшләнә башлаган һәм игътибарга лаекле тагын бер проект – татар батыры образын кайтару. Әлеге проект үз эшчәнлеген «Туган авылым» милли-туристик комплекс һәм Диния нәзарәте белән бергәлектә алып бара. Батыр образын кайтару өчен, «Туган батыр» персонажы эшләнә. Ул яңа татар әкиятләре, комикслары, компьютер уеннары, мультфильмнар өчен герой булып хезмәт итәчәк. Бу проект Президентның мәдәни башлангычлар фондының грантына ия булды.

2021 елны Диния нәзарәте чираттагы зур медиапроектны тормышка ашырып тәмамлый. Ул да булса: «Хузур ТВ» телеканалының тавыш яздыру студиясе, эфирда күрсәтү өчен, дөньякүләм танылган «Билал» мөселман мультфильмын татар теленә тәрҗемә итте. «Билал» – Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең танылган сәхабәсе Билал бине Рабах радыяллаһу ганһенең биографиясе турында бәян иткән тарихи-маҗаралы тулы метражлы анимация. Мультфильм дөньяның 11 теленә тәрҗемә ителгән инде, хәзер ул «Хозур ТВ» телеканалы тамашачылары өчен татар телендә дә «сөйләшәчәк».

■ **dumrt.ru** сайтыннан

# Игелек кылыйк!




Фото: shutterstock.com

2021 елда Диния нәзарәте социаль юнәлештәге эшчәнлекне дәвам итте һәм, халыкның мохтаҗ катламнарына ярдәм күрсәтү өчен, мөһим башлангычларны актив рәвештә тормышка ашырды. Хәйрия проектлары Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды һәм мөхтәсибәтләр тарафыннан өч төп юнәлеш – авыру балаларга дәвалану өчен финанс ярдәм күрсәтү, мохтаҗларны азык-төлек белән тәэмин итү һәм инвалид балалар тәрбияләүче гаиләләрне социаль яктан тернәкләндерү буенча гамәлгә ашырылды.

Мәсәлән, 2021 елда ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды җәлеп ителгән акчалар ярдәмендә 160 авыру бала һәм олыларның тернәкләндерү курслары һәм техник чаралар сатып алу өчен чыгымнарны каплады.

Шунысы игътибарга лаек: фондның авыруларга ярдәмне аеруча Рамазан аенда актив күрсәтергә мөмкинлеге арта. Быел «Рамазан – игелекле гамәлләр ае» акциясе кысаларында, 21 баланы тернәкләндерү өчен, акча җыелды. Моннан тыш, шул ук хәйрия марафоны нәтиҗәләре буенча, мохтаҗларга 1 млн сум фитра садакасы түләнде.

«Зәкят» хәйрия фондының тагын бер мөһим проекты – «Инвалид балаларны, кече яшьтәге инвалидларны һәм аларның ата-аналарын социальләштерү буенча «Хәят» үзәге». Әлеге үзәк «үзенчәлекле» балаларны социальләштерү, аларда мөстәкыйльлек һәм көнкүрештә җайлашу күнекмәләре тәрбияләү, шулай ук ата-аналарының эмоциональ яктан аруын булдырмау максатыннан оештырылды.

Үзенчәлекле балалар һәм аларның әти-әниләре өчен «Хәят» үзәгенә йөрү бушлай. 2021 елда «социализация» курслары буенча 951 дәрес үткәрелде.

ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды тарафыннан 2021 елда 5252 гаиләгә азык-төлекләтә ярдәм күрсәтелде. Корбан ите, ризык җыелмалары һәм гошер садакасы азкеремле, инвалид балалар тәрбияләгән, тулы булмаган гаиләләр һәм өлкән яшьтәге ялгыз кешеләргә тапшырылды. Шулай итеп, Корбан бәйрәме көннәрендә фонд 27,4 тонна корбан итен 2622 гаиләгә, 13 социаль оешмага, 11 төзәтү учреждениесенә һәм 10 мөселман уку йортына таратты. Рамазан ае чорында тагын 807 азкеремле гаилә азык-төлек җыелмалары алды. Мохтаҗлар файдасына республика мәчетләре тырышлыгы белән 577,33 тонна ашелчә җыелды һәм тапшырылды. Казанда «Зәкят» хәйрия фонды әлеге кампания кысаларында 400 дән артык азкеремле гаиләне 14,5 тонна гошер садакасы белән тәэмин итте. Моннан тыш, ел дәвамында «Зәкят» фондыннан 1423 кешегә 9 тонна азык-төлек җыелмалары бирелде.

«Зәкят» хәйрия фондының даими хәйрия ашларында йортсыз-җирсез, ятим, физик мөмкинлекләре чикләнгән, өлкән яшьтәге ялгыз 5150 кешегә кайнар ашлар өләшенде. Шулай ук, агымдагы елда 2810 кеше сезонлы кием-салым һәм аяк киеме белән тәэмин ителде.

■ **dumrt.ru** сайтыннан

# АЛТЫ ШАРТ

Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйткән:

**«Ул сезнең белән бергә. Аллаһы сезнең ни кылганнарыгызны күрә».**

«Әл-Хәдид / Тимер», 57:4

Ибраһим бине Әдһәм рахимәһуллаһи исемле галим янына бер кеше килә дә:

– Әй, Ибраһим хәзрәт, минем гөнаһ кыласы килә, гөнаһлар эшләргә миңа рөхсәт бир, – дип мөрәҗәгать итә.

Галим аңа:

– Әгәр дә алты шартымны үтәсәң, сиңа гөнаһ эшләргә рөхсәт бирәм, – ди.

Теге бәндә үзенә күрә шатланып: «Нинди шартлар ул, әйт миңа, мин барысына да әзер», – дип әйтә.

Ибраһим бине Әдһәм мондый сүзләр әйтә:

1. Әгәр дә гөнаһ кыласың килсә, Аллаһы Тәгалә күрмәслек урын тап.

– Аллаһы Тәгалә һәр әйберне һәр җирдә күреп тора һәм күңелебездә булган бөтен уйларыбызны да белә. Мин Аннан берничек тә кача алмыйм.

2. Гөнаһ кыласың килсә, Аллаһының ризыгын ашама.

– Мин моны һич тә булдыра алмыйм, чөнки бөтен җирдә дә Аллаһының ризыгы, ә мин ашамыйча тора алмыйм, – ди теге бәндә.

Шуннан Ибраһим хәзрәт дәвам итеп:

3. Аллаһы Тәгалә бар иткән һәм син атлап йөри торган җир өстендә яшәмә, – дип әйтә.

– Җир, мәшрик (көнчыгыш) вә мәгъриб (көнбатыш), бөтен галәм (космос) барысы да – Аллаһыныкы. Ничек мин җирне ташлап каядыр китә алыйм?

Беребезнең дә фатирында яки өендә әхлаксыз кешене торгызасы килми, бигрәк тә ул өебездә тәртипсезлек эшләсә, без аңа түзә алмыйбыз. Ә ни өчен Аллаһының өе булган җирдә без тәртипсез соң?! Ни өчен үзебез билгеләгән кануннар белән нәфесебезгә бирелеп, Аллаһының җирендә яшибез?! Ә үзебез өебездә тәртипсез кешене яратмыйбыз! Ә Аллаһы ни өчен безнең тәртипсезлекне яратырга тиеш соң?! Аллаһыдан курыкырга кирәк, чөнки бөтен әйбер Аллаһыныкы: җир дә, һава да, хәтта тәнебез дә без теләгәнчә түгел, ә Аллаһы теләгәнчә эшли.

4. Үлем фәрештәсе синең җаныңны алырга килгәндә: «Бар, кит минем янымнан», – дип, үлемеңне кичектерә алсаң, гөнаһ эшләргә сиңа рөхсәт итәм, – ди галим, дәвам итеп.

– Бу һич тә мөмкин хәл түгел. Үлемнән бер кешенең дә кача алганы юк әле. Мин дә үлемне берничек тә кичектерә алмыйм.

Шуннан соң Ибраһим бине Әдһәм рахимәһуллаһи:

5. Әгәр дә гөнаһ кыласың килсә, сине кабергә салганда яныңа килеп сорау ала торган Мөнкир белән Нәкир исемле фәрештәләр сорау бирә башласа, син: «Мин сезнең сорауларыгызга җавап бирмим, мине тынычлыкта калдырыгыз», – дип, җаваптан борыл, – дип әйтә.

– Бу хәл мөмкин түгел хәзрәт! Әле бер кеше дә бу сораулардан кача алмаган.

Шунда Ибраһим Әл-Әдһәм: «Соңгысын тәкъдим итәм, әгәр дә эшли алмасаң, кайгы вә хәсрәт сиңа», – дип әйтә.

6. Сине фәрештәләр җәһәннәмгә алып барганда, син: «Мин анда бармыйм», – дип борыл да җәннәткә таба юнәл.

– Әй, хәзрәт, кем миннән сорап торыр?! Мине алырлар да, шунда ук җәһәннәмгә ташларлар. Бу шартларны үтәү мөмкин түгел, хәзрәт!

Шунда Ибраһим хәзрәтләре сорау бирә: «Ә синең тагын тәкъдимнәрең бармы? Тагын каядыр котылу чарасын күрәсеңме?»

Теге гөнаһлы кеше җавап итеп: «Юк, башка чара күрмим», – дип әйтә.

Шунда Ибраһим Әл-Әдһәм рахимәһуллаһи: «Алайса, гөнаһ кылма! Тәүбә кылып, Аллаһының кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшә, синең котылуың шунда чагыла», – дип әйтә.

Коръәни Кәримдә болай дип әйтелгән:

**«Әйт: «Ий үз-үзләренә каршы зарарда булган колларым! Аллаһының рәхмәтеннән өметегезне өзмәгез, чөнки Аллаһы [ширектән тыш] барлык гөнаһларны да ярлыкый!» Һичшиксез, Ул – [гөнаһларны күпләп] Гафу итүче, Рәхимле».**

«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:53

Әй кардәшләрем! Көннәрнең бер көнендә күңелегездә гөнаһ фикерләре уянса, гөнаһ «орлыклары»н кулыгызга тотып, аларны чәчәр өчен гомер бакчагызга чыксагыз, ул гөнаһ «орлыклары»нда үкенечле, хәсрәтле җимешләрне күрергә тырышыгыз һәм аларны юк итү ягын карагыз. Ибраһим бине Әдһәм рахимәһуллаһиның гөнаһ эшләргә теләгән кешегә әйткән сүзләрен һәрвакытта исебездә тотыйк.

■ **«Тимергали хәзрәт вәгазьләре»** китабыннан



Фото: shutterstock.com

# Сөләйман галәйһиссәлам кыйссасы

*(Дәвамы. Башы алдагы санда)*

## Дөньядан китүнең вакыты һәм урыны – үзгәрешсез

Сөләйман галәйһиссәлам, хаким булып, көн саен кешеләрнең гозерләрен тыңларга һәм аларның борчуларын хәл итәргә вакыт тапкан. Бервакыт, мохтаҗлар белән шундый әңгәмәләрнең берсендә, аның янына бик тә мәртәбәле бер кеше кергән. Сөләйман каршында үзенең борчулары турында сөйләүче хәерченең утыруын күреп, ул аңа бик тә текәлеп карый башлаган. Аның карашы шулкадәр көчле булган ки, теге мескен куркуга калган һәм Сөләйман галәйһиссәламнән болай дип сораган:

– Ий, Аллаһының илчесе! Миңа явызлык белән караучы бу кеше кем?

Сөләйман галәйһиссәлам моның кунакка килгән Газраил галәйһиссәлам булуын әйткән. Әлеге кеше «Газраил» сүзен ишетү белән үк, агарынып, куркудан калтырый башлаган. Коточкыч халәттә һәм дулкынланып ул Сөләйман галәйһиссәламгә түбәндәге сүзләр белән мөрәҗәгать иткән:

– Ий, Аллаһының илчесе! Мин Газраил галәйһиссәламнең миңа явызлык белән каравын күрдем. Ул мине карашы белән көлгә әйләндерергә әзер иде. Аллаһы Тәгалә сиңа шундый хакимлек биргән ки, Ул сиңа хайваннарны һәм кошларны, шулай ук җилне һәм ташларны буйсындырган. Синнән сорыймын ки, җилгә әмер бирep, ул мине моннан еракка, Һиндстанга алып китсә иде. Бу урыннан еракка китеп, мин Газраил галәйһиссәламнең явызлыгыннан имин булырмын.

Сөләйман галәйһиссәлам бу кешене кызганган һәм, аны Һиндстанга күчерү өчен, җилгә әмер биргән. Җил исә, әмергә буйсынып, аны элэктереп алган да, ерактагы Һиндстан тавына илтеп ташлаган.

Аннары Сөләйман галәйһиссәлам Газраил галәйһиссәламнән сораган:

– Ий, Газраил! Ни өчен син миңа килгән кешегә шулкадәр текәлеп карадың? Нигә син аны куркыттың?

Газраил галәйһиссәлам аның соравына болай дип җавап биргән:

– Ий, Аллаһының илчесе! Мин бу кешегә явызлык белән карамадым. Мин ул кешегә гаҗәпләнү белән карадым. Мине шунысы гаҗәпләндерде: ул – монда, ә Аллаһы Тәгалә бу кешенең җанын миңа Һиндстанда алырга боерды. Мин уйга калдым: «Мин әмерне үти алыр өчен, кыска гына вакыт аралыгында бу кеше ничек Һиндстанда була алачак?» Ул синнән җилгә әмер биреп Һиндстанга илтүен сорагач, миңа барысы да аңлашылды.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«...Вакытлары җиткәч, аны бер сәгатькә генә дә артка да, алга да күчерә алмаслар».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:61

## Ризыкны Аллаһы бирә

Сөләйман галәйһиссәлам җил һәм җен белән идарә иткән, шулай ук бөҗәкләрнең, кошларның һәм хайваннарның телен аңлаган. Бервакыт кырмыска белән сөйләшеп, Сөләйман галәйһиссәлам аннан елга никадәр азык кирәк булуы турында сораган. Кырмыска аңа болай дип әйткән:

– Мин елына бер бодай орлыгын ашап бетерәм.

Әлеге сүзләрнең дөреслегенә ышану өчен, Сөләйман галәйһиссәлам бер пыяла савытка бодай орлыгын һәм кырмысканы салган да, капкачын ябып куйган.

Бер ел узгач, Сөләйман галәйһиссәлам әлеге савытны ачкан һәм кырмысканың бары ярты орлыкны гына ашап бетергәнен күргән. Шулвакытта Сөләйман галәйһиссәлам кырмыскага бер ел элек булган сөйләшү хакында искә төшергән:

– Син елына бер бодай орлыгын ашап бетерәм дигән идең. Әмма күрәм, син бары яртысын гына ашагансың.

Моңа җавап итеп, кырмыска аңа болай дип әйткән:

– Әйе, барысы да дөрес, мин елына бер бодай орлыгын ашап бетерәм. Әмма моңа кадәр миңа азыкны Аллаһы Тәгалә биргән иде һәм мин Аның рәхмәтенә өмет багладым. Ә хәзер минем ризыгым көчсез кеше кулына калды. Мин синең мәрхәмәтле булуыңа ышанмадым һәм бары ярты орлыкны гына ашадым, ә калган яртысын киләчәк көннәргә калдырдым.

Бу хакта Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйткән:

**«Җирдә Аллаһы ризык бирмәгән бер генә җан иясе дә юк. Ул аларның урнашкан урыннарын да, [аналарының карыннарыннан алып, үлгәннәреннән соң дәфен ителгәнчегә кадәр] саклана торган урыннарын да белә. [Бөтен җан ияләренең саны, ризыклары, урыннары, әҗәлләре – боларның] һәммәсе дә ап-ачык [Ләүхүл-Мәхфүз исемле] бер китапта [язылган]».**


«Һуд», 11:6

## Кырмысканың догасы

Бервакыт Сөләйман галәйһиссәламнең иләндә корылык һәм ачлык башлана. Дәүләт башлыгы буларак, ул үз халкы белән бергә яңгыр сорап, Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итәргә карар кылган. Гыйбадәт кылу урынына бару юлында аның игътибарын бер кырмыска җәлеп иткән. Шул кечкенә генә бөҗәк, аягын өскә күтәреп, аркасына ятып дога кылган. Тыңлап торганнан соң, Сөләйман галәйһиссәлам кырмысканың Аллаһыга ничек ялварганын ишеткән. Кырмыска болай дип дога кылган:

– Ий Аллаһы! Син безне бар кылдың. Син бүләкләгән язмышта без Синең рәхмәтеңә мохтаҗбыз. Башкаларның җинаятe сәбәпле, безне һәлак итмәвеңне үтенәм.

Шулвакытта Җәбраил галәйһиссәлам килгән һәм әлеге кырмысканың догасы кабул булуы турында хәбәр биргән. Сөләйман галәйһиссәлам


Фото:dumrt.ru

җыелган халыкка мондый сүзләр белән мөрәҗәгать иткән:

– Кире кайтыгыз. Яңгыр килүен сорап тиешле дога кылынды инде. Бу кырмыска Аллаһыга мөрәҗәгать итте һәм аның догасы кабул ителде.

Менә шулай, кеп-кечкенә кырмысканың бөек һәм ихлас догасы сәбәпле, тулы бер халык ачлыктан котылуга ирешә. Хакыйкатьтә, Аллаһы безне бары тәкъвалыгыбыз һәм иман ныклыгы дәрәҗәсенә карап хөкем итә.

## Сөләйман галәйһиссәлам һәм кырмыска

Сөләйман галәйһиссәлам үзенең зур гаскәре белән юлга чыкканда, кырмыска белән бәйле тагын бер вакыйга булган. Юлда ул янә кырмыскалар күче белән очрашкан. Алар арутална белми кышка әзерләнгәннәр. Сөләйман галәйһиссәламнең гаскәрен күреп, ана кырмыска мондый әмер биргән:

– Ий кырмыскалар! Сөләйман галәйһиссәлам гаскәре сезне ялгыш таптап китмәсен, юл бирегез һәм ояга кереп яшеренегез.

Сөләйман галәйһиссәлам ана кырмысканың әмерен ерактан ук ишетеп елмайган һәм, кырмыскалар ояларына кереп качарга өлгерсеннәр өчен, үзенең хәрбиләренә дә туктарга кушкан.

Фәхреддин Әр-Рази үзенең тәфсирендә бу вакыйгага бәйле болай дип әйтә:

«Кырмыскаларга ояларына керергә әмер бирелә. Ана кырмыска нидән курка соң? Ана кырмыска, Сөләйман галәйһиссәлам хакимиятенең санын, күплеген, зурлыгын күрә калсалар, эшче кырмыскалар Аллаһы аларны бүләкләгән нигъмәтләргә карата рәхмәтсез булырлар, дип курка».

Бу вакыйга хәтта Коръәни Кәримдә дә чагылыш тапкан:

**«[Шамның] Кырмыскалар [белән тулы бер] үзәненә барып җиткәч, [аларның хөкемдарлары булган] бер ана кырмыска: «Ий кырмыскалар! Ояларыгызга керегез! Сөләйман [галәйһиссәлам] һәм аның гаскәрләре сезне абайламыйча таптамасын!» – диде».**

«Ән-Нәмл / Кырмыскалар», 27:18

Кырмыска турындагы хикәяттә бер хаким иясе үзенең кул астындагыларга бөек хикмәт, ә икенче берсе чын мәгънәсендә миһербанлык үрнәге күрсәтә. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Сез барыгыз да көтүчеләр һәм үз көтүегез өчен җавап тотасыз...», – дип әйткән. Ә Сөннәт барлык заманнар өчен мәңгелек булып тора, һәм аңа һәр кеше, шул исәптән, хөкемдарлар да үзенең гадел идарә итүе белән иярергә тиеш. Шул чагында алар Аллаһының һәм үз халыкларының ризалыгына лаек булачак.

Бәрәкәтле идарәнең нигезе – үзеңнең кул астында эшләгән барлык кешеләрнең дәрәҗәсенә, байлыгына, диненә һәм милләтенә карамастан, зирәк һәм гадел булу дигән сүз. Ә халыкның бурычы – Аллаһы Тәгалә тарафыннан тәкъдир кылынган җитәкче артыннан бару. Карагыз: Сөләйман галәйһиссәлам нинди бөек хаким булган, шуңа аның даны мең еллар узгач та тынмый! Раббыбыз барлык дәүләт җитәкчеләрен һәм хакимнәрне гадел һәм киң күңелле кылса иде. Коръәндә әйтелгәнчә, хәтта бөҗәк тә хакимлек итүчеләрне якларга тырыша бит.

■ **Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН,**
Татарстан Республикасы мөфтие

# Ни өчен вакытның бәрәкәте бетте?



Фото: shutterstock.com

Кешенең иң кыйммәтле әйбере – аның вакыты. Шуңа да карамастан, күбебез вакытыбызга тиешле игътибар бирми. «Ихтыяҗ тәкъдимне тудыра», – диләр. Күңел ачу индустриясенең үсүенә карап, вакыт сарыф ителүнең тормышыбызда ни дәрәҗәдә урын алуы хакында нәтиҗә ясарга мөмкин.

Миллионнарча кешеләр бүген асылда бердәнбер әйбер – вакытны «үтерү» өчен чаралар күрү һәм булдыру белән мәшгуль. Кино, телевидение, төрле комарлы уеннар, компьютер уеннары – болар барысы да безнең иң кыйммәтле ресурсыбыз – вакытыбызны юк итү кораллары булып тора.

Иблиснең безгә каршы куллана торган иң тәэсирле чарасы – алда әле яхшы гамәлләр кылу өчен күп вакыт булуына ышандыру һәм бездә, кулдан килгәнне теләсә кайсы вакытта кабат кайтара алуыбыз хакында фикер уяту. Ләкин без шуны онытабыз: һәр яңа көн безгә бик тирән мәгънәле сүзләр белән мөрәҗәгать итә: «Әй, Адәм баласы, менә мин – яңа көн, мин синең гамәлләреңә шаһит. Син мине яхшылык өчен файдалан, югыйсә, әгәр мин китсәм, Кыямәт көненә кадәр беркайчан да кайтмаячакмын».

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Дүрт нәрсә турында соралмыйча, Кыямәт көнендә кешенең аягы кымшанмаячак: аның гомере һәм аны ничек уздырганы турында; аның яшьлеге һәм аны ничек кулланганы турында; аның мал-мөлкәте һәм аны нәрсәгә сарыф иткәне, аның гыйлеме һәм аның белән нәрсә эшләгәне турында».

Бу хәдистән күренгәнчә, без узган көннәребез, аларны ничек һәм нәрсәгә сарыф итүебез турында аерым соралачакбыз. Бу – яшьлек көннәренең ни дәрәҗәдә мөһим булуын күрсәтә.

Башка бер билгеле хәдистә җиде төркем кешеләр турында әйтелә: алар Кыямәт көнендә күләгә астында булачаклар, шул ук вакытта калганнар эсселектән һәм сусаудан интегәчәкләр. Бу төркемнең берсе – яшьлекләрен Аллаһыга хезмәт итүгә багышлаган мөэминнәр. Алар Иблиснең вәгъдәләренә бирелмәгән, Аллаһы Тәгаләгә хезмәт итүне соңга калдырмаган. Ул бәндәләр тормышның иң яхшы көннәре өчен иң яхшы гамәлләр сайлады һәм Аллаһы Тәгалә аларны сайлады, башкалардан өстен итте.

Шулай булгач, яхшы гамәлләрне соңга кичектерү турында фикер килгән вакытта, бу уйның кемнән килгәнен белеп торыгыз һәм үзегезне югалтмагыз.

Вакытның мөһимлеген аңлаган кешенең һәр сәгате кадерле, әмма шуңа да карамастан, бу дөньяда тормышны әһәмиятсез максатларга сарыф иткән кешеләр дә бик күп. Мондый кеше тулысынча үз тормышын әһәмиятсез максатларга ирешүгә багышларга мөмкин, ләкин ул үзенең кем булуын, бу дөньяга ничек килүен, ни өчен монда булуын һәм тормыш вакыты тәмамланганнан соң кая юнәләчәген аңларга тырышу өчен хәтта бер сәгать тә таба алмый.

Безне Аллаһы Тәгалә яратты һәм Аннан башка һичкем кешенең тормышы өчен иң хәерле гамәлләрнең нинди буласын белә алмый. Әйдәгез, бу иң мөһим сорауга җавап табу өчен, Аллаһы китабына мөрәҗәгать итик.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә: **«Мин җеннәрне һәм кешеләрне Миңа гыйбадәт кылсыннар дип яраттым».**

«Әз-Зарият / Таратучылар», 51:56

Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылу – кеше омтылырга тиешле булган бердәнбер максат. Гыйбадәт белән бәйле булмаган бар нәрсә мөэмин өчен мәгънәсез. Дин белән аз таныш булучылар өчен, тормышның максаты итеп гыйбадәтне сайлаган кешеләр шулкадәр сәер һәм заһид (аскет) итеп, бөтен тормышы газаплануларда узган кеше кебек күренә. Ләкин, чынлыкта, дөньяны үзенә табыну юлы итеп сайлаган дөнья колына караганда, чын мөэмин юлы күпкә бәхетлерәк.

Беренчедән, аңа дөньядагы барлык байлыклардан баш тарту кирәкми, ул бөтен дөньяның байлыкларына ия булырга һәм, шуңа да карамастан, Аллаһы Тәгаләнең тәкъва колы булып калырга мөмкин.

Хәдисләрдә күргәнебезчә, бу дөньяда үзен һәм гаиләсен тәэмин итү һәм башкаларга ярдәм итү өчен үз вакытын сарыф иткән бәндә Аллаһы Тәгалә юлында зур гыйбадәтләр кылучылардан санала. Бөтен хикмәт – ниятебездә, Кыямәт көнендә дә ниятебезгә карата әҗерләр бирелер.

Икенчедән, хәтта ул хәерчелеккә һәм бәхетсезлеккә дучар булса да, авырулар аңа боз яуган кебек коелып төшсәләр дә, шул вакытта да ул, иман иясе булганга күрә, бу дөньяда бәхетле булачак. Әгәр дә сез күп айлар дәвамында нинди дә булса ярышларда җиңәр өчен әзерләнеп, бөтен вакытын шуңа сарыф итүче спортчыны күрсәгез, сез аны бәхетсез кеше дип әйтә аласызмы? Ул үзенең җиңүче булачагын уйлап, максат куеп йөргәндә үк бәхетле булачак. Ләкин җәннәт белән чагыштырганда нинди дер ярышларда җиңү нәрсә соң ул?! Шулай булгач, ни рәвешле кайгы-хәсрәтләрне сабырлык белән кичереп, күп вакыт сәҗдәдә һәм гыйбадәттә булып, җәннәткә өметләнеп яшәүчене бәхетсез дип санарга мөмкин?!

Пәйгамбәребезнең хәдисендә болай дип әйтелә: «Аллаһы юлында булучының хәле нинди гаҗәп. Чынлап та, аның хәлендә бөтен нәрсә аның өчен яхшы һәм бу мөэминнән башка беркемгә дә бирелмәгән. Әгәр дә аны шатландырган берәр нәрсәгә төшенсә, ул Аллаһыга шөкер итә һәм бу аның өчен хәерле булачак. Әгәр дә ул бәхетсезлеккә дучар икән, ул сабырлык күрсәтә һәм бу да аның өчен хәерле булачак».

Өченчедән, Аллаһы Тәгалә гыйбадәттә тырышлык күрсәтүче колларының калебләрен нурландыра һәм яктырта. Йөрәге шул якты нур белән балкыган кеше дә киң күңелле була, төннәрен намазда үткәрә. Бер изге кеше әйтүенчә: «Гыйбадәт ияләренең төннәре, күңел ачкан кешеләрнең төннәренә караганда, ләззәтлерәк».

Аллаһы Тәгаләгә хезмәт итү юлын сайлаган кешегә кирәк булган беренче нәрсә – белем. Белем белән эшләнгән хәтта аз санлы эшләрдән дә гаять зур файда алырга мөмкин, ә белемсез, күпме генә зур эшләр булса да, алардан файда булмаска мөмкин.

Белем алу зур тырышлык таләп итә һәм бу юлга баскан кеше, беренче чиратта, вакытны контрольгә алырга һәм аны юкка сарыф итмәскә тиеш. Бары тик шулай гына олуг галимнәр ирешкән уңышка ирешергә мөмкин. Кайсыбыз белем алуга көннең бер сәгатен сарыф итә алмый? Көн саен бер сәгать булса да сарыф итсәк, без бик күп нәрсәгә ирешә алабыз. Беренчедән, без белем алуга багышланган сәгать – гыйбадәттә уздырган сәгать ул. Алай гына да түгел, бу гыйбадәтләрнең иң яхшысы дип санала. Ислам галиме Әз-Зөһри әйтүенчә: «Гыйлем алу бөтен гыйбадәтләр арасында Аллаһы Тәгалә каршында иң яхшысы». Икенчедән, дөньяви булып күренгән эшләрне дә без белем ярдәмендә изге гамәлләргә әверелдерә алабыз. Өченчедән, белем белән эшләнгән гыйбадәтнең кыйммәте күп тапкырлар арта. Шуңа күрә вакыт нинди кыйммәткә ия булуын аңлаган кешегә белем алуга көненә берничә минут булса да вакыт бирергә кирәк.

Аллаһы каршында оттырганнар арасында калмас өчен, без изге гамәлләр кылуга күп игътибар итәргә тиеш. Әмма, изгелекләребез уңышлы булсын өчен, безгә вакытны дөрес файдаланырга өйрәнү кирәк.

Эшнең кыйммәте күп шартларга бәйле һәм гамәлләрнең кыйммәтен сизелерлек арттыра торган шартларның берсе – гамәл кылынган вакыт.

Һәр инсан үз көнен тигез шартларда башлый. Бай булсак та, ярлы булсак та, безнең 24 сәгать вакытыбыз бар. Һәркем бу бәһасез байлыкны ничек тотарга икәнен хәл итә һәм аны ни рәвешле тотуыбыз, Кыямәт көнендә хәлебезнең нинди булачагына бәйле.

Ул көнне кешеләр, Аллаһыга иман китерү сүзләрен әйтер өчен, бу дөньяда җыйган бөтен малмөлкәтләрен бирергә әзер булыр. Ләкин аларның беркайчан да мондый мөмкинлекләре булмаячак. Башкалар бәхет ияләре булыр, чөнки, ниһаять, аларның йокылары, изге гамәлләре дә Аллаһы хозурында гыйбадәт булып язылачак. Бу, һичшиксез, тормыш мизгелләренең кадерен белгән һәм аларны юкка сарыф итмәгән кешеләр булачак.

■ **Марат хәзрәт САЛӘХОВ,**
ТР МДНнең Дәгъват бүлеге белгече

# Пәйгамбәрләр кылган догалар

*Дога кылу мөэмин-мөселман кешесе өчен гыйбадәт. Дога кылуны без үз телебездә, күңелебездә булган сүзләребез белән дә, сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм әйтеп, өйрәтеп калдырган хәдис-шәрифләр белән дә, бөек галимнәребез, олуг остазларыбыз кылган догалар үрнәгендә дә башкара алабыз.*


Фото: shutterstock.com

Шулай ук Изге Китабыбыз Коръәни Кәримдә дә Раббыбызның динен таратырга, адәм балаларын һидаятькә чакырырга җибәрелгән пәйгамбәрләребезнең кылган догалары урын алган. Алар үрнәгендә без дә төрле хәлләрдә калганда Раббыбызга мөрәҗәгать итә, Аннан ярдәм сорый алабыз. Аллаһы Тәгалә, һичшиксез, ихлас күңелдән, Аның рәхмәтенә, ярдәменә өметләнеп кылган догаларны кабул итәр. Моңа ышанайык һәм тормышыбызны догалы итик. Һәр көнебезне, эшебезне доgадан, «Бисмиллаһи» дигән сүзләрдән башлыйк. Дога кылу – ул безнең күңелләребезне нурландыра, тынычландыра, безне динебез Исламда ныгыта һәм Раббыбызга якынайта. Аллаһы Тәгалә кылган догаларыбызны кабул итеп, безне һидаять-тәүфикътан аермаса иде.

## Адәм галәйһиссәлам белән Хавва анабызның догалары

Атабыз Адәм галәйһиссәлам белән анабыз Хавва радыяллаһу ганһә, җәннәттән чыгарылгач, шушы доганы кылганнар:

رَبَّنَا ظَلَمْنَا أَنْفُسَنَا وَإِنْ لَمْ تَغفِرْ لَنَا وَتَرْحَمْنَا لَنَكُونَنَّ مِنَ الْخَاسِرِينَ

«Раббәнәә ӟаләмнәә әңфүсәнәә вә илләм тәгъфирләнәә вә тәрхәмнәә ләнәкүүнәннә минәл-хаасириин».

**«Ий Раббыбыз! Без [әмереңә каршы төшеп, үзебезне җәннәттән чыгарырлык эш эшләп] үз-үзләребезгә золым иттек. Әгәр дә Син безне гафу итмәсәң һәм безгә мәрхәмәт итмәсәң, без зарар күрүчеләрдән булырбыз».**

«Әл-Әгъраф / Кыртәләр», 7:23

## Нух галәйһиссәламнең догасы

Нух галәйһиссәламнең улы аның белән бергә көймәгә утырмаган һәм Нух галәйһиссәлам Аллаһыга: Йә Раббым! Әлбәттә, улым минем гаиләмнәндер. Синең вәгъдәң хактыр, аны җиренә җиткерерсең. Син хакимнәрнең Хакиме (гаиләмне коткарачагыңа сүз биргән идең, хәзер улыма нәрсә булачак?) дип дога кылган. Аңа Аллаһы Тәгалә: «Әй Нух! Ул синең гаиләңнән түгел, чөнки ул дөрес булмаган гамәл ияседер. Белмәгән нәрсәңне миннән сорама, синең җаһилләрдән булуыңны теләмим», — дигән. Бу сүзләргә Нух галәйһиссәлам:

رَبِّ إِنِّي أَعُوذُ بِكَ أَنْ أَسْئَلُكَ مَا لَيْسَ لِي بِهِ عِلْمٌ وَإِلاَّ تَغفِرْ لِي وَتَرْحَمْنِي أَكُنْ مِنَ الْخَاسِرِينَ

«Рабби инниии әгууӟү бикә ән әс-әлүкә мәә ләйсә лии биһи гыйльмүн вә илләә тәгъфир лии вә тәрхәмнииәкүм-минәл-хаасириин».

**"Ий Раббым! Мин белмәгән бернәрсәне Синнән соравымнан Сиңа сыенам. Әгәр мине ярлыкамасаң һәм мине кызганмасаң, [һичшиксез] мин зарар күрүчеләрдән булырмын».**

«Һуд», 11:47

## Лут галәйһиссәламнең догасы

Лут пәйгамбәр кавемен дингә өнди иде. Әмма кавеме аны тыңларга теләмәде. «Бу сөйләгәннәреңнән баш тартмасаң, илеңнән куылачаксың", – дип аны куркыттылар. Моңа Лут галәйһиссәлам:

رَبِّ نَجِّنِي وَأَهْلِي مِمَّا يَعْمَلُونَ

«Рабби нәҗҗинии вә әһлии мимммәә йәгъмәлүүн».

**«Ий Раббым! Болар кылган нәрсәләрдән мине һәм гаиләмне коткар», –** дип дога кылды.

«Әш-Шүгәра / Шагыйрьләр», 26:169

Лут галәйһиссәламнең кавеме белән бәйле булган тагын бер догасы бар:

رَبِّ انْصُرْنِي عَلَى الْقَوْمِ الْمُفْسِدِينَ

«Раббиңсурнии галәл-каумил-мүфсидиин».

**«Ий Раббым! Бозык кавемгә каршы миңа ярдәм ит!»**

«Әл-Ганкәбут / Үрмәкүч», 29:30

## Ибраһим галәйһиссәламнең догасы

رَبَّنَا إِنَّكَ تَعْلَمُ مَا نُخْفِي وَمَا نُعْلِنُ وَمَا يَخْفَى عَلَى اللَّهِ مِنْ شَيْءٍ فِي الْأَرْضِ

وَلاَ فِي السَّمَاءِ. اَلْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي وَهَبَ لِي عَلَى الْكِبَرِ إِسْمَاعِيلَ وَإِسْحَاقَ

إِنَّ رَبِّي لَسَمِيعُ الدُّعَا. رَبِّ اجْعَلْنِي مُقِيمَ الصَّلاَةِ وَمِنْ ذُرِّيَّتِي رَبَّنَا وَتَقَبَّلْ دُعَا رَبَّنَا اغْفِرْ لِي وَلِوَلِدَيَّ

وَلِلْمُؤْمِنِينَ يَوْمَ يَقُومُ الْحِس

«Раббәнәә иннәкә тәгъләмү мәә нүхъфии вә мәә нүгълинү вә мәә йәхъфәә галәллааһи миң шәй-иң фил-әръдый вә ләә фис-сәмәә-и. Әлхәмдү лилләәһилләӟии вәһәбә лии галәл-кибәри исмәәгыйлә вә исхәәка иннә раббии ләсәмигуд-дүгаа. Раббиҗгальнии мүкыймәсәләәти вә миң ӟүрийәти раббәнәә вә тәкаббәл дүгаа. Раббәнәгъфир лии вә ли вәәлидәййә вә лил-мүэминиинә йәүмә йәкуумүл-хисәәб»

**«Әй Раббыбыз! Яшерен һәм ачык булган һәрнәрсәбезне Син беләсең. Җирдә дә, күктә дә Аллаһыдан яшерен бернәрсә дә калмас. Карт хәлемдә миңа Исмәгыйльне һәм Исхакны биргән Аллаһыга мактау булсын. Һичшиксез, Раббым доганы кабул итүчедер. Раббым! Мине намаз кылучылардан әйлә: нәселемнән дә шундый инсаннар чыгар. Әй Раббыбыз! Догабызны кабул әйлә. Әй Раббыбыз! Хисап соралачак Кыямәт көнендә мине, ата-анамны һәм бөтен мөэминнәрне гафу әйлә».**

«Ибраһим» 14:38-41

Хәзрәти Ибраһим галәйһиссәламнең Кәгъбә нигезе янында кылган догасы:

Хәзрәти Ибраһим галәйһиссәлам улы Исмәгыйль галәйһиссәлам белән бергә Кәгъбәнең нигезләрен күтәргәндә шушы доганы кылганнар:

رَبَّنَا تَقَبَّلْ مِنَّا إِنَّكَ أَنْتَ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ

«Раббәнәә тәкаббәл миннәә. Иннәкә әнтәс-сәмиигуль галиим».

**«Йә Раббыбыз! Эшебезне кабул ит! Син Ишетүче һәм күңелләрне Белүче» .**

«Әл-Бәкара»/Сыер, 2:127

## Ибраһим һәм Исмәгыйль галәйһимуссәламнең догалары

Ибраһим галәйһиссәлам белән Исмәгыйль галәйһиссәлам Кәгъбәне төзеп бетергәч кылган дога:

رَبَّنَا وَاجْعَلْنَا مُسْلِمَيْنِ لَكَ وَمِنْ ذُرِّيَّتِنَا أُمَّةً مُسْلِمَةً لَكَ وَأَرِنَا مَنَاسِكَنَا وَتُبْ عَلَيْنَا إِنَّكَ أَنْتَ التَّوَّابُ الرَّحِيمُ * رَبَّنَا وَابْعَثْ فِيهِمْ رَسُولًا مِنْهُمْ يَتْلُو عَلَيْهِمْ آيَاتِكَ وَيُعَلِّمُهُمُ الْكِتَابَ وَالْحِكْمَةَ

وَيُزَكِّيهِمْ إِنَّكَ أَنْتَ الْعَزِيزُ الْحَكِيم

«Раббәнәә вәҗгәльнәә мүслимәйни ләкә вә миң ӟүррийййәтинәә үммәтәм мүслимәтәл ләк. Вә әринәә мәнәәсикәнәә вә түб галәйнәә иннәкә әнтәт-тәвввәбүр-рахиим. Раббәнәә вәбгаҫ фииһим расүүләм минһүм йәтлүү галәйһим әәйәәтикә вә йүгаллимүһүмүль китәәбә вәл хикмәтә вә йүзәккииһим. Иннәкә әнтәл газиизүль-хәкиим».

**"Ий Раббыбыз! Безне Сиңа [чын күңелдән] буйсынучылардан ит, нәселебездән – Сиңа гына итагать иткән бер [мөселман] өммәтне [үстер], безгә гыйбадәт урыннарыбызны күрсәт һәм [вазифаларыбызны үтәгәндә кылган хатакимчелекләребезне гафу итеп] тәүбәбезне кабул әйлә! Һичшиксез, Син – Тәүбәләрне кабул итүче, Рәхимле. Ий Раббыбыз! Алар арасыннан Синең аятьләреңне укыячак, Китапны һәм Хикмәтне өйрәтәчәк һәм аларны [ширек, азгынлык һәм шуның ише матди-рухи нәҗесләрдән] сафландырачак бер пәйгамбәр җибәр! Һичшиксез, Син – Бөек [Җиңелмәс], Хикмәт иясе".**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:128-129

رَبَّنَا آتِنَا فِى الدُّنْيَا حَسَنَةً وَ فِى الآخِرَةِ حَسَنَةً وَ قِنَا عَذَابَ النَّارِ

«Раббәнәә әәтинәә фид-дүньйәә хәсәнәтәү вә фил әәхыйрати хәсәнәтәү вә кыйнәә гаӟәәбән-нәәр».

**«Ий Раббыбыз! Безгә дөньяда да яхшы нәрсәләр бир, Ахирәттә дә яхшы нәрсәләр бир һәм безне Утның газабыннан сакла!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:201

■ Сәхифәне **Айсылу ЮЛДАШЕВА** әзерләде

# «Билал» мультфильмы татар телендә күрсәтеләчәк

Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын йомгаклап һәм Идел буе Болгар дәүләтендә исламны кабул итүнең 1100 еллыгын каршылап, «Хозур ТВ» телеканалы, эфирга чыгару өчен, «Билал» исемле дөньядагы иң популяр мөселман мультфильмын татарчага тәрҗемә итте. Бу уңайдан, 13нче декабрьдә, әлеге яңа медиапроект журналистлар өчен тәкъдим ителде. Аларның сорауларына Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан мөфтие урынбасары, нәзарәтнең «Хозур» нәшрият йорты җитәкчесе Ришат Әхтәм улы Хәмидуллин, «Хозур ТВ» телеканалының баш мөхәррире Исмәгыйль Гыйндуллин, шулай ук тавышландыручы актерлар җавап бирде.

Очрашуда әлеге фильм рухи һәм әдәп-әхлак кыйммәтләрен алга сөрүен, документаль фактларга нигезләнүен, теләсә кайсы татар баласы аңлый алырлык гади, йөгерек телдә эшләнүен, анимация дөньясында бик зур урын тотуын, фильмны татар телендә әзерләү һәм тавышландыру буенча тәрҗемәче һәм актерларның күп хезмәт куюларын билгеләп үттеләр.

"Билал" – Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең танылган сәхабәсе Билал бине Рабах радыяллаһу ганһенең тәрҗемәи хәле турында бәян иткән тарихи-маҗаралы тулы метражлы анимацион фильм. Мультфильм дөньяның 11 теленә тәрҗемә ителгән инде, хәзер ул «Хозур ТВ» телеканалы тамашачылары өчен татар телендә дә «сөйләшәчәк».

Фильмны тавышландыруда танылган татар артистлары һәм театр актерлары: Данияр (Әбри) Хәбриев, Резедә Сәлахова, Илдар Кыямов, Зөлфәт Зиннуров, Алмаз Сабирҗанов, шулай ук мәктәп укучысы Аслан Миргаязов катнашты. Бу составта алар мультфильмның 14 персонажы өчен 16 төрле тавыш яздырган. Билал картинада Әбри Хәбриев һәм Аслан Миргаязов тавышы белән сөйләшә.



Тәрҗемәчеләр, мөхәррирләр, тавыш режиссерлары һәм дублерларның иҗат командасы алдында сценарийны төрле тел үзенчәлекләрен – фонема, морфема, лексик, синтаксик һәм лингвистик үзенчәлекләрне исәпкә алып тәрҗемә итү бурычы торды. Аларга һәр персонажның сөйләмен татар сөйләменә якынлаштырырга һәм экранда геройларның әйткән сүзләрен авыз ачу рәвешләренә туры китерергә, аларның холкын сүз һәм тавыш ярдәмендә күрсәтергә, сөйләм билгеләнгән вакытка (тайминг) сыешырга һәм сюжетның асылын аудиториянең интеллект дәрәҗәсенә һәм яшенә яраклаштырырга туры килде. Дубляж 4 айда эшләнеп, әлеге эшкә 15 белгеч җәлеп ителде.

Мультфильм сюжеты буенча, Билал исемле малай мәхәббәт тулы күркәм гаиләдә туган. Ул кечкенәдән үк искиткеч матур тавышы белән башкалардан аерылып торган һәм бөек сугышчы булырга хыялланган. Әмма көннәрдән бер көнне чит җирләрдән вәхши җайдаклар килеп, аларның авылын басып ала һәм апасы белән Билалны урлап китеп коллыкка сата.






Шул рәвешле, Билалның бәхетле балачагы өзелә. Сабыйлар бөтенләй башка дөньяга килеп эләгәләр. Алга таба Билал куркыныч, мәрхәмәтсез дөньяда яшәргә мәҗбүр була, әмма бу аның рухын сындырмый. Әкренләп ул хыялын тормышка ашыруга таба бара һәм батыр йөрәкле, гадел сугышчы булып үсә. Гаҗәеп гүзәл, моңлы тавышы белән ул Ислам һәм дөнья тарихына җәмәгать намазына чакырган беренче мөәзин буларак кереп кала.

«Билал» картинасы BroadcastPRO Middle East премиясендә иң яхшы инновацион мультфильм булып танылган. Кинематографның иң зур базасы булган IMDb тарафыннан 2018 елның 10 иң шәп фильмнары рәтенә кертелгән. Мультфильм трейлерын YouTube'та 10 миллионнан артык кеше караган.

Татар телендәге «Билал» мультфильмы «Хозур ТВ» телеканалында эфирга 1 гыйнварда, кышкы каникуллар вакытында чыгачак. Ул бөтен гаилә белән утырып карау өчен яхшы.

Бүгенге көндә «Хозур ТВ» телеканалы Рәсәйнең 9 төбәгендә күрсәтә. Эфирга «Хозур ТВ» телеканалы үзе әзерләгән тапшырулар, шулай ук, нәфис фильмнар һәм сериаллар, балалар өчен кызыклы тапшырулар, барлыгы 200 дән артык программа чыгарыла. **YouTub**тагы рәсми каналда язылучылар саны 1 миллионнан артып киткән, контентны караучылар саны 170 миллионны тәшкил итә. «Хозур ТВ» тапшыруларын **huzurtv.ru сайты, App Store яки Google Play**да каналның мобиль кушымтасы аша карарга мөмкин.

■ **dumrt.ru** сайтыннан
Фотолар **dumrt.ru** сайтыннан

# Беренче кеше – беренче пәйгамбәр

Иң баштан Раббыбыз Аллаһы Тәгалә атабыз Адәм галәйһиссәламне барлыкка китергән, ә аннан соң аның кабыргасыннан анабыз Хавва радыяллаһу ганһәне халык кылган. Аллаһы Тәгалә аларга бар нәрсәне дә күрсәткән, аларның атамаларын өйрәткән. Адәм галәйһиссәлам «Хавва» дияргә, ә хәзрәти Хавва «Адәм» дияргә өйрәнгән. Барлык кеше алардан – атабыз Адәм һәм анабыз Хавվадан барлыкка килгән һәм җир йөзе буйлап таралган. Шул рәвешле, төрле халыклар, төрле телдә аралашучылар барлыкка килгән. Әмма кешеләр тән төсләре белән аерылсалар да, чәчләре бераүләрнең чем кара, икенчеләрнең сары төстә булса да, үзара төрле телләрдә аралашсалар да – аларның барысының да бер ата һәм ана – ул атабыз Адәм галәйһиссәлам белән анабыз Хавва радыяллаһу ганһә. Төрле булсак та, бер-беребездән аерылып торган кебек тоелсак та, барыбызның да бер йөрәк, бер баш, ике кул һәм ике аяк. Шуңа күрә дә без бер-беребездән берни белән дә аерылмыйбыз. Һәм иң мөһиме: безнең акылыбыз бар. Ул булмаса, без бу Җир йөзендә яши алмас идек, бөтен нәрсәгә дә өйрәнә дә алмас идек. Акыл ярдәмендә без үзебезгә кадәр булганнар хакында беләбез, бу якты җир йөзе кешеләргә вакытлыча гына бирелгән нигъмәт икәнлеген аңлыйбыз. Болар хакында без Изге Китабыбыздан укып беләбез.

Адәм галәйһиссәламгә кадәр Раббыбыз фәрештәләр һәм җеннәр диган затларны халык кылган. Аллаһы Тәгалә фәрештәләргә җир йөзендә кешеләрне халык кыласын әйткәч, алар: «Йә, Раббыбыз, без Сиңа гыйбадәт кылабыз, Сине бөеклибез, Сиңа хәмед-сәналәр әйтәбез. Әмма кешеләр җир йөзендә гаделсезлек таратыр дип борчылабыз», – дип әйткәннәр. Бу сүзләренә каршы Раббыбыз аларга фәрештәләр белмәгәнне белүен әйткән һәм беренче кеше – атабыз Адәм галәйһиссәлмне халык кылган, аңа җан биргән.

Раббыбыз Аллаһы Тәгалә Адәм галәйһиссәламгә кояшны – кояш, айны – ай, туфракны – туфрак, җилне җил дип атарга өйрәткән. Әмма моңа кадәр фәрештәләргә боларны өйрәтмәгән булган. Раббыбыз Адәм галәйһиссәламне һәм аннан туган балаларны башка затлардан олуграк иткән. Адәм галәйһиссәламнең барлык әйберләрнең атамасын әйтеп чыгуын ишеткәч, фәрештәләр аның олуглыгын таныганнар, әмма бары тик Иблис кенә тәкәбберләнеп, Адәм галәйһиссәламнән йөз чөергән, Аллаһының бөеклеген танып, Адәм галәйһиссәламгә сәҗдә кылудан баш тарткан. Моның сәбәбен үзенең уттан, ә атабыз Адәмнең балчыктан яратылуында дип әйткән. Бу гамәле белән Галәмнәрнең Яратучысына каршы барган. Әгәр уйлап карасак, утның да, балчыкның да Яратучысы бер – Ул Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә. Һәм Адәм галәйһиссәлам акыл һәм ихтыяр көче белән нигъмәтләнгәнгә күрә, өстен булган.

Дәвамы киләсе санда, нәни дустым!



■ Сәхифәне
■ **Айсылу ЮЛДАШЕВА**
әзерләрде




دين ومعيشت

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

## Игътибар!

## «Дин вә мәгыйшәт» газетасы яңа форматта

Хөрмәтле укучыларыбыз! 2022 елның гыйнвар аеннан газетабыз яңа форматта (А4) басыла башлый. Басмабызда түбәндәгеләр хакында укып белә аласыз:

динебез һәм милләтебез язмышына кагылышлы мәкаләләр;
гыйбрәтле кыйссалар;
Ислам шәригатенә кагылышлы язмалар;
пәйгамбәрләр тарихы һ.б.

Газетабызга түбәндәге ысуллар белән язылырга мөмкин:

– Почта бүлекчәләре аша.
– "Почта Росии"нең телефон өчен кушымтасыннан.
– Онлайн ысул белән.

# Ни өчен намаз укыйбыз?

Кечкенә чакта мәчеткә йөргәндә хәзрәтебез: «Балалар, без ни өчен намаз укыйбыз, җәннәткә керер өченме, әллә Аллаһы Тәгалә бездән риза булсын өченме?» – дип сораган иде. Без югалып калдык һәм безнең өчен бу гадәти хәл иде. Мәчет-мәдрәсәгә йөргән, Аллаһы Тәгаләнең җәннәт дип аталган матур урыны барлыгын белгән бала, әлбәттә, аның турында хыялланачак, күз алдына китерергә тырышачак, һәр гамәл-гыйбадәтен кылганда да, җәннәткә эләгү хыялы белән йөриячәк. Балаларга кечкенәдән динебезнең күркәм якларын, җәннәт дигән гаҗәеп матур һәм рәхәт урын барлыгын аңлату, шуңа омтылырга өйрәтү күркәм гамәл. Әмма без үсә барган саен «Аллаһының рәхмәте, ризалыгы» дигән берни белән дә алыштырып булмый торган бөек төшенчәләр барлыгын аңладык. Без Аллаһы бездән риза булса, Аның рәхмәтендә булсак, нинди хәлдә дә бәхетле булачагыбызны аңлау дәрәҗәсенә җиттек. Бу инде, чыннан да, бөек нигъмәт иде.

Шуңа да кечкенә чагыбызда бирелгән сорауга җавапны без үсә төшкәч таптык: без гамәл-гыйбадәтләребезне Аллаһы ризалыгы өчен кылабыз, чөнки һәр нигъмәткә, шул исәптән җәннәткә дә бары тик Раббыбыз рәхмәте белән ирешәчәкбез. Олуг фикһ галиме Әбү Ләйс Сәмәркандинең «Тәнбиһүл гафилин» («Ваемсызларны уяту») китабының «Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән өмет ителә торган нәрсә» бүлегендә шундый хәдис риваять ителә:

«...Аллаһының бәндәләреннән берәү бар иде. Ул тау башында биш йөз ел Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылды. Ул тауның озынлыгы һәм киңлеге утыз аршын, эче утыз аршындыр. Ул тауны диңгез чорнаган, һәр тарафыннан дүрт мең фәрсахтыр (фәрсах – үлчәү берәмлеге (ред.). Аллаһы Тәгалә аңа бармак киңлеге ләззәтле су белән тәмле чишмәне агызды, ул су тау астында җыелыр. Аңа агачны бирде, һәр көнне ул агачтан аның өчен анар җимеше (гранат җимеше) чыгар. Һәрвакыт уянганнан соң, тәһарәт алып, бу гранатны алып ашый, моннан соң намазга баса иде. Үзенең Раббысына сәҗдә кылган вакытта аның җанын алуны сорады. Аллаһы Тәгалә аның өчен моны эшләде. Җәбраил галәйһиссәлам болай дип әйтте: «Без аның яныннан үткәндә һәм без җиргә төшкәндә яки күккә ашканда, ул үз хәлендә һаман сәҗдәдә иде». Җәбраил галәйһиссәлам әйтте: «Без аны гыйлемдә табабыз. Дөреслектә, ул Кыямәт көнендә кубарылыр һәм Аллаһы Тәгалә каршында туктатылыр. Аллаһы Тәгалә аңа болай дип әйтер: «Колымны Минем рәхмәтем сәбәпле җәннәткә кертегез». Ул кол әйтер: «Бәлки гамәлем сәбәпледер». Аллаһы Тәгалә Үзенең фәрештәләренә әйтер: «Колымны, аның булган нигъмәтен һәм гамәлен үлчәгез». Күз нигъмәте табылыр, дөреслектә ул колның биш йөз еллык гыйбадәтен каплар, тән нигъмәте калыр. Аллаһы Тәгалә әйтер: «Минем колымны утка кертегез». Аны тәмугка илтерләр. Ул: «Үзеңнең рәхмәтең белән, әй, Аллаһым, мине җәннәткә керт», – дип кычкырыр. Аллаһы Тәгалә: «Аны кайтарыгыз», – дип әйтер. Ул кол Аллаһы Тәгалә хозурында туктатылыр һәм Аллаһы Тәгалә аңа әйтер: «Әй, бәндәм, сине кем яратты? Син һичнәрсә түгел идең». Кол әйтер: «Әй, Аллаһым, Син яраттың». Аллаһы Тәгалә әйтер: «Йә, бу бар кылуым синең гамәлең яки Минем рәхмәтем сәбәплеме?» Кол: «Синең рәхмәтең сәбәпле яратылдым», – дип әйтер. Аллаһы Тәгалә: «Сине биш йөз ел гыйбадәткә кем куәтләндерде?» – дип сорар. Кол: «Син – минем Раббым», – дип җавап бирер. Аллаһы Тәгалә: «Диңгез уртасындагы тауга сине кем иңдерде һәм тозлы судан тәмле суны кем чыгарды? Һәр кичен анарны (гранатны) сиңа кем чыгарды? Ул елга бер мәртәбә генә чыга иде. Син Миннән җаныңны сәҗдә хәлендә алуны сорадың, сиңа моны да кылдым. Моны сиңа кем кылды?» – дип сорар. Бу кеше: «Син, әй, Аллаһым», – дип җавап бирер. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтер: «Боларның һәркайсы рәхмәтем сәбәпле һәм рәхмәтем белән сине җәннәткә кертәм». Җәбраил галәйһиссәлам: «Һәрнәрсә Аллаһының рәхмәте белән генәдер», – дип әйтте».

Әгәр уйлансак, телебезне ешрак шөкер итәргә өйрәтсәк, зарлану кебек гадәтләрдән арынсак, гаплади төшенчәләрне аңлар идек: гамәл-гыйбадәт кылуыбыз, Раббыбыз юлында, һидаятьтә булуыбыз, намазлар укып, шәригать буенча яшәвебез – ул Аллаһының безгә биргән чиксез нигъмәте, рәхмәте. Һәм без моның өчен Раббыбызга рәхмәтле булырга тиеш. Әгәр шуны аңлап, һәр көнебезне Аның ризалыгы өчен үткәрсәк, иншәАллаһ, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә дә ирешербез. Ә Раббыбызның рәхмәтенә ирешүчеләргә Аның күркәм вәгъдәсе бар: ул – җәннәт.

Раббыбыз Аллаһы Тәгалә күңелләребезгә пакьлек, һидаять салып, безне рия, тәкәбберлек кебек нәфес авыруларыннан саклап, гомеребез буе Аллаһының ихлас коллары булып яшәвебезне насыйп итсә иде.

■ **Айсылу ЮЛДАШЕВА**



Фото: shutterstock.com

# Йошио Имаидзуми: японлының Ислам динен кабул итүе




● *Садык Йошио Имаидзуми (1905-1960)*

Фото: Япония мөселманнары чыгарган Islamic Culture Forum журналыннан



● *Габдерәшит Ибраһимов белән Садыйк Йошио Имаидзуми*

Фото: Япония мөселманнары чыгарган Islamic Culture Forum журналыннан




● *Токиодагы мәчет.* Фото: beautifulmosgue.com



● *Японлылар һәм Габдерәшит хәзрәт Ибраһимов.* Фото: biyografya.com

Йошио Имаидзуми 1905 елның 16 нчы сентябрендә сәнгать остасы һәм антиквариатлар сатучы гаиләсендә дөньяга килгән. Башлангыч һәм урта белем алуны тәмамлаганнан соң, Йошио Токиодагы Нихон университетына укырга керә һәм 1927 елда инженер-механик белгечлеген алып, укуын тәмамлый. Шул ук елны Йошио Имаидзуми «Меишо Электрик Лимитед» оешмасының металл эшләнмәләр җитештерү бүлегенә инженер булып эшкә урнаша. Биредә ул радио һәм очкычлар өчен кирәкле булган эшләнмәләр җитештерә. Оешмада Йошио 1930 елның мартына кадәр эшли. Шул елның апрелендә Япониянең почта һәм телекоммуникацияләр Министрлыгына почтмейстер вазифасына алына.

## Ислам динен кабул итүе

Имаидзуминың йорты Рәсәй мөселманнарының лидеры булган татар имамы Габдерәшит Ибраһимовның йорты янәшәсендә булган. Беренче тапкыр Габдерәшит хәзрәт Японияга 1902-1903 елларда килгән, бу кыска гына вакытлы сәфәр булган. Икенче тапкыр ул биредә 1908 елда килгән һәм Япония җитәкчелеге тарафыннан бик күркәм рәвештә каршы алынган.

Йошио Имаидзумига әлеге шәхес белән элемтәләр булдыру мөмкинлеге туган. Габдерәшит Ибраһимовның киңәшен тыңлап, Йошио Имаидзуми Токиодагы җирле төрек-татар җәмәгатьчелеге белән аралаша башлаган. Япониядә яшәүче татар-мөселманнары белән булган элемтәләре нәтиҗәсендә, Йошио Имаидзуми Ислам дине хакында белгән һәм мөселманнарның яшәү рәвешен күзәтеп, Йошио мөселман кешесе булырга карар кылган – 1929 елның март аенда рәсми рәвештә Ислам динен кабул иткән. Аның Ислам диненә күчү йоласын Токиодагы төрек-татар җәмәгатьчелегенең башлыгы Габделхәй хәзрәт Корбангалиев башкарган.

Йошио Имаидзуми үзенә Садыйк Йошио Имаидзуми исемен алган һәм зур кызыксыну белән Ислам дине нигезләрен өйрәнә башлаган.

Аның укытучысы һәм нәсыйхәтчесе Габдерәшит хәзрәт Ибраһимов булган. Ул 1933 елда Японияга кайтып, гомеренең соңгы көненә кадәр, ягъни 1944 елга чаклы шунда яшәгән. Шунысы мөһим: Габдерәшит хәзрәт Япониядә Ислам динен таратуда зур роль уйнаган. Аның тырышлыгы белән, йөзләгән японлы Ислам динен кабул иткән. 1938 елда төрек-татар җәмәгатьчелеге тарафыннан Токиода мәчет салынган. Аның беренче имамы Габдерәшит хәзрәт булган. Мәчет төзелү белән Япониядә Ислам дине үсеш алган.

## Икенче Бөтендөнья сугышы вакытында

1933 елда Садыйк Имаидзуми, почтмейстер булып эшләгән вакытта, Саеко исемле кызга өйләнгән, ул Ислам динен кабул иткәннән соң Садыйка исемен алган.

1941 елдагы Икенче Бөтендөнья сугышы вакытында Япония Тын океанында агрессив сугыш хәрәкәтләре башлый. Яшен тизлегендәге кампания барышында Япония Азия континентының бик күп җирен, шулай ук Тын океаны һәм Һиндстанның көнбатыш өлешендәге утрауларны ала.

Япониянең хәрби диңгез көчләре югары командованиесе Садыйк Имаидзумины, мөселман халкы яши торган көньяк оккупацияләнгән территорияләрдә эшләү өчен, даими булмаган граждан хезмәткәре сыйфатында эшкә чакырып ала.

Югары командование аны 1943 елның июнь аенда, регионның мөселман җәмәгатьчелегенә машина төзү проектларының техник инструкторы буларак, Макассар шәһәренә җибәрә (хәзер Индонезиядәге Сулавеси). Ноябрь аенда Садыйк Имаидзуми Борнео утравындагы Банджармасин шәһәренә күчерелә. Биредә ул мөселман җәмәгатьчелегенең инженерлык эшчәнлегендәге проектларда киңәшче булып эшли. Җирле халык белән аралашып, ул мөселманнар тормышы белән күбрәк таныша.

Икенче Бөтендөнья сугышы һәм Тын океанындагы сугыш, Япониянең җиңелүе һәм оккупацияләнүе белән, 1945 елның август азагында тәмамлана. Голландиялеләр яңадан Һиндстандагы элеккеге колонияләрен кайтарып алалар. Ул арада колонияләрдә милли-азатлык хәрәкәте үсә башлый.

Күп кенә элеккеге японлы солдатлар һәм Япония армиясенең гражданлык хезмәткәрләре индонезияле көрәшчеләргә азатлык өчен ярдәм итә. Садыйк Имаидзуми да шулар арасында була. Әмма 1946 елда голландиялеләр тарафыннан кулга алына. Һәм нидерландлыларга карата дошманлыкта гаепләнеп, хәрби трибуналга бастырыла. Тик хәрби трибунал аны гаепсез дип таба һәм ул азат ителә. Шул ук елның июнь аенда Садыйк Имаидзуми Японияга озатыла.

(*Дәвамы киләсе санда*)

■ **Дамир ГАЙНЕТДИНОВ** язмасы, **islam-today.ru** сайтыннан тәрҗемә

# Үзен күңел төшенкелегендә дип уйлаучылар хакында

***Еш кына, бигрәк тә, соңгы елларда күп тапкырлар күңел төшенкелеге сүзен ишетергә туры килә. Тыйб (медицина) галимнәре арасында «күңел төшенкелеге» чирме ул яки юкмы дигән бәхәсләр бар. Ләкин күп очракларда «күңел төшенкелеге» сүзе астында кеше үзенең эшсезлеген, күңел төшенкелеген, һөнәрсез йөрүен яшерә.***



Фото: shutterstock.com

Сөбеханаллаһ! Әгәр Коръәнне ачып карасак, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләренә күз салсак, дөньяның эш урыны булуын, рәхәтләнеп кәеф таба торган урын түгел икәнлеген, изгелекләр эшләргә вакыт җиткәнлеген белербез. Һәм һәрбер мөселман дөнья тормышыннан соң мәңгелек Ахирәт киләчәгенә иманы камил булырга тиеш.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Һичшиксез, Без кешене михнәт эчендә яраттык».**

«Әл-Бәләд / Шәһәр», 90:4

Аятьтән аңлашылганча, кешенең тууыннан алып авырлыклар башлана. Адәм баласының шул авырлыкларны чишеп яшәве – олы хикмәт. Карагыз, ана баласын нинди авырлыклар белән дөньяга китерә. Баласы тугач озак та үтми, аның авырлыклары онытылып, ул сөенечкә, шатлыкка күмелә. Аның бит газиз нарасые туган. Шуннан соң бу сабый үсә: укый, эшкә урнаша, аннары гаилә кора, йорт һәм башка хуҗалык кирәк-яракларын таба. Берсе дә җиңел генә кесәгә керми, тырышлык күрсәтергә кирәк. Менә шуңа күрә Аллаһы Тәгалә кешене авырлыкларда яраттык дип әйтә.

Коръәни Кәримнең түбәндәге аятендә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

**«Ул, сезнең кайсыгыз гамәлләренә күрә күркәмрәк булуын сынар өчен, үлемне һәм тереклекне яратты [сезнең кылачакларыгыз хакында әзәли гыйлемен уртага чыгарачак, соңыннан Үзенең гыйлеменә күрә түгел, кылганнарыгызга күрә әҗерләрегезне бирәчәк]. Ул – Бөек [Җиңелмәс], [гөнаһларны күпләп] Гафу итүче».**

«Әл-Мүльк / Хөкемдарлык», 67:2

Сынар өчен дигән сүз – дөньяның сынау, имтихан урыны икәнлеген күрсәтә. Һәм менә шул сынау җиңел булмас, әлбәттә. Сынауны үтәр өчен тырышлык куярга кирәк.

Шулай ук хәдисләрдә Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Пәйгамбәрләр иң зур сынауларга очраган Аллаһы коллары», – дип әйтә. Ләкин бик күп сынауларга дучар булсалар да, алар гомерләрен Аллаһы риза булган хәлдә үткәрергә тырыштылар.

Димәк, дөнья җиңел булмас. Җиңел булган булса, без Аллаһы Тәгалә биргән нигъмәтләрнең тәмен дә сизмәс идек, кадерен дә белмәс идек. Эшләп тапкан акчаңа да күп тырышлыклар куелса, син аның кадерен күбрәк беләсең. Ләкин әгәр җиңел генә керсә, шулай ук җиңел генә чыгып та китә. Нәкъ менә шуңа күрә күп очракта тумыштан байлыкка күмелеп, гомерендә бер көн дә эшләмәгән кешеләр ахырда бик бәхетсез булалар, гомерләре бик аяныч тәмамлана, тормышның түмән югалталар. Кызганыч, күп кенә кешеләр үзләрен күңел төшенкелегендә дип уйлыйлар. Ләкин, чынлыкта, эшсезлектән килеп чыккан сагыш кына борчый аларны.

Бер галим турында болай дип язалар: «Әхмәд остаз кешеләргә ярдәм итәргә бик нык ашыкты. Ул болай дип әйтә иде: «Син кешегә ярдәм иткән саен Аллаһы да сиңа ярдәм итәчәк. Нәкъ менә шул сәбәпле ялкаулар иң бәхетсез, иң кәефсез, иң боек кешеләрдер. Аларның бер сөенечләре, бер шатлыклары юктыр. Һәм аларга капма-каршы як кешеләр – аларга бер дә охшамаган эш ияләре. Нәрсә белән шөгыльләнсәләр дә, алар гел башка төрле булырлар».

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә бер хәдисендә болай дип әйтте: «Кем кардәшенә ярдәм итүдә булса, Аллаһы да аңа ярдәм итүдә булыр». Шуңа күрә әгәр нинди дә булса хәрәкәт белән мәшгуль булсаң, башыңа кәефне төшерә торган фикерләр килмәс.

Халык арасында киң таралган бер кыйсса бар. Ул кыйсса бер карашка көлкә булса да, анда бик зур гыйбрәт бар. Бер хатын-кыз елап утыра икән. Ник елыйсың дип сорагач, менә килер бер вакыт һәм мин кияүгә чыгармын. Кияүгә чыккач малай табармын. Ул малай әзрәк үскәч иптәшләре белән су буена барыр. Шунда уйнар һәм суга батып үләр. Шуңа кайгырып елап утырам, дигән. Бу бит күңел төшенкелегенә бирелеп утыруның ап-ачык бер чагылышы. Бер нәрсә эшләмичә утыргач, башка уйфикерләр килә башлый. Ә безнең баш мие шулай ясалган ки, әгәр берәр уй килеп керсә, без аны күпертергә яратабыз. Ахыр чиктә гади генә бер фикер зур кайгыга әверелергә мөмкин. Нәкъ менә теге хатын кебек. Башта кияүгә чыгармын. Аннары бала туар. Бала шундый матур булыр, яратырмын. Аннары үсәр, аннары уйнар да, аннары суга батар. Менә шулвакытта әгәр без тик утырыр урынга нинди дә эш белән мәшгуль булсак, ул уйларны уйларга вакыт калмас иде. Баш мие башка әйберләр турында уйлар иде. Хәзер инде күңел төшенкелеген бетерә торган берничә киңәшне бирәсем килә:

### 1. Аллаһыдан ярдәм сорагыз

Бөтен тормыш авырлыкларында да иң элек сыену урынын Аллаһыдан эзләгез. Ничек кенә булмасын, нинди генә авырлыклар, уй-фикерләр килмәсен, Аллаһы Тәгалә ул авырлыкларны бетерергә кодрәтле.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Һичшиксез, [Раббыларының чиксез нигъмәтләрен инкяр иткән] кяферләр кавеме генә Аллаһының рәхмәтеннән өметен өзә».**

«Йосыф», 12:87

Коръәндә пәйгамбәрләрнең сүзләре дә китерелә. Алар «кайгымны һәм сагышымны бары тик Аллаһыга гына юллыйм», «Күркәм сабырлык күрсәтәм, бәлки Аллаһы улларымның барысын да кайтарыр» диделәр. Бу ике аять Ягъкуб галәйһиссәлам сүзләре иде. Шулай ук Әюб галәйһиссәлам хакында Коръәндә болай дип искә алына:

**«[Расүлем!] Әюб галәйһиссәламне дә искә ал]! Менә ул [каты чир белән авырып, еллар буена сабыр иткәннән соң, намазга тора алырлык та көч таба алмагач] Раббысына [дога белән] endәште: «Һичшиксез, миңа бер зарар кагылды. Син исә мәрхәмәтлеләрнең иң мәрхәмәтлесесең».**

«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:83

### 2. Күңел дәвасы – намаздыр

Аллаһы Тәгалә безне намазда тынычлык табарга өйрәтте. Намазыбыз безне тынычландыра торган бер дәва булып тора. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте:

**«Ий иман китерүчеләр! Сабырлык һәм намаз аша [Аллаһы Тәгаләдән] ярдәм сорагыз. Һичшиксез, Аллаһы сабыр итүчеләр белән».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:153

### 3. Кешегә файда китерү, изгелектә булу

Хәдистә әйтелә: «Аллаһыга иң сөекле кешеләр – иң күп файда китерүчеләр. Аллаһыга иң сөекле гамәл – мөселман йөрәгенә сөенеч, шатлык китерә торган гамәл, аның кайгысын бетерә торган гамәл яки аның бурычын түләп бетерү яки аны ашатып ачлыгын бетерү. Миңа бер ай буена мәчеттә игътикяф кылудан да якынрак эш – мөселманның мәшәкатен бетерүдә булган эштер».

### 4. Хикмәт иясе белән киңәшләшү

Килеп чыккан проблемаларны чишүдә хикмәт иясе, гыйлем иясе, зур тормыш тәҗрибәсе туплаган акыл иясе белән киңәшләшү дә күңел төшенкелегенә бирелүдән үтемле чара булып тора, чөнки нәрсә генә әйтсәк тә, ничек кенә заманабыз үзгәрсә, кулыбыздагы айфоннар, андроидлар пәйда булса да, машиналарның гади бензин белән эшли торганы гына түгел, ә электр белән йөри торганнары булса да, безнең арабызда килеп чыга торган проблемалар – алар бөтенесе бик борынгы. Вакыт үзгәрә бара, ә безнең проблемалар шул ук кала. Шуңа күрә тәҗрибә туплаган хикмәт ияләре Аллаһының рәхмәте белән чыгу юлларын күрсәтерләр, иншәАллаһ. Һәм инде ахыр сүземдә, әлбәттә, зикерләр – Аллаһыны искә алу, Аллаһыга дога кылу – бөтен кайгыхәсрәтне бетерә торган дәва булып тора.

Аллаһы Раббыбыз безне бәлаказалардан сакласа иде! Тормышларыбызны күркәм һәм сөенечле кылса иде. Әмин.

**Сәлимҗан хәзрәт ДОМНИН,**
Кабан арты мәчете имамы

# Өмме Руман радыяллаһу ганһә

***Исеме:*** *Зәйнәб бинте Гамер бине Өвәймир бине Габдешәмс бине Әттаб Әл-Кинания радыяллаһу ганһә*
***Куньясе:*** *Өмме Руман*

## Мәккәгә мәхәббәте

Өмме Руман яшьли Габдулла бине Хариска кияүгә чыккан. Аларның Тофәйл исемле уллары туган. Озакламый бу гаилә Йәмәннең Серат шәһәреннән Мәккәгә күченеп килгән. Мәккәдә аларга Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе бик нык ярдәм иткән.

## Яңа гаилә

Мәккәгә күченеп килгәннән соң, озак та үтми Өмме Руманның ире вафат булып, хатыны тол калган һәм аның таяныч булырдай бер кешесе дә булмаган. Котәйлә бинте Габделгоззәгә өйләнгән Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе бу тол калган хатынны кызганып, үзенә кияүгә чыгарга тәкъдим ясаган. Бу никахтан аларның Габдерахман исемле уллары һәм Гайшә исемле кызлары туган.

## Ислам динен кабул итүе

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең пәйгамбәрлеге килгәннән соң, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһенең беренче хатыны Котәйлә бинте Габделгоззә ислам динен кабул итүдән баш тарткан. Шул сәбәпле, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе бу хатыны белән аерылган, ләкин балалары (Әсма һәм Габдулла) әтиләре белән калганнар.

Өмме Руман радыяллаһу ганһә ислам динен кабул иткән. Ул үз балаларын һәм иренең беренче никахтан булган балаларын да бертигез күргән, бертөрле яраткан һәм күркәм тәрбия биргән.

Өмме Руман радыяллаһу ганһә ислам дине хөкемнәрен тиешенчә үтәп барырга тырышкан, күп нәрсәләрне үзенең иреннән өйрәнгән.

Бервакыт Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе хатынының намаз гыйбадәтен үтәгән вакытта гәүдәсен әле уң якка, әле сул якка авыштырганын күргән һәм бу гамәле өчен хатынын шелтәләгән. Өмме Руман радыяллаһу ганһә үз хаталарын тиз арада төзәтергә тырышкан.

Гайшә радыяллаһу ганһәдән хәбәр ителә: «Атасы йортына килгәндә, аскы катта – Өмме Руман радыяллаһу ганһә, ә югары катта – Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе булган. Аларның икесе дә Коръән укыганнар» (имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан).

## Тугры хатын

Өмме Руман радыяллаһу ганһә һәрвакытта да ире өчен ныклы таяныч булган. Бигрәк тә корәешлеләр тарафыннан эзәрлекләүләр көчәйгәч, шактый авыр вакытларда, ул иренә терәк булырга, аңа ярдәм итәргә тырышкан. Түбәндәге вакыйга моңа дәлил булып тора.

Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән мәгарәдә, мөшрикләрдә яшеренеп яткан вакытта, алар янына Әбү Бәкер радыяллаһу ганһенең Габдулла исемле улы килеп, хәл белешеп йөргән. Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе улына өйдә булган акчаларны алып килергә кушкан. Улы әтисенең үтенечен үтәгән. Әбү Бәкер радыяллаһу ганһенең әтисе Әбү Кухафә үзенең килененә: «Әбү Бәкер өй акчаларын нәрсә өчен тотты? Үз-үзен корбан итүе генә җитмәгән, инде гаилә акчаларын да тарата», – дип әйткән. Өмме Руман радыяллаһу ганһә кайнатасы алдында иренең намуслы исемен аклап, хикмәт белән аны тынычландыра алган.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән Мәдинәдә булганда, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе Габдулла исемле улына хат язган. Хатында гаиләсенә Мәдинәгә күченеп килүләрен үтенгән. Өмме Руман радыяллаһу ганһә балалары белән бергә авыр һәм ерак юлга кузгалган.

Өмме Руман радыяллаһу ганһә гел ирен хуплаган һәм барлык эшләрендә дә аңа ярдәм иткән. Фәкыйрь сәхабәләр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мәчете тирәсендә яшәгәннәр. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең хәллерәк сәхабәләренә болай дип әйткән: «Кемнең өендә ике кешелек ризык булса, ул ризыкны өченче кеше белән бүлешсен. Кемдә дүрт кешелек ризык булса, бишенче кеше белән бүлешсен». Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе гаиләсендә өч кеше яшәвенә карамастан, ул ун кешелек ризык китергән.

## Ана йөрәге

Мәдинәгә һиҗрәт кылган вакытта Өмме Руман радыяллаһу ганһә кызы Гайшә радыяллаһу ганһә белән бер дөягә утырганнар. Дөя чабып киткән. Шулвакытта Өмме Руман радыяллаһу ганһә үзе турында онытып: «Ий, минем кызым!» дип борчылган. Дөянең йөгәннәре кулдан ычкынып, дөя әле уң, әле сул якка чапкан. Арттарак булган кешеләр аларга ярдәм иткәннәр, дөяне туктатканнар. Шул рәвешле Өмме Руман радыяллаһу ганһә кызы Гайшә радыяллаһу ганһә белән Мәдинәгә исән-имин килеп җиткәннәр.

Өмме Руман радыяллаһу ганһәнең кызы Гайшә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә кияүгә чыккан. Гайшә радыяллаһу ганһә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне мәрхүмә хатыны Хәдичә радыяллаһу ганһәгә бик көнләгән. Мәрхүмә хатыныннан көнләшеп, Гайшә радыяллаһу ганһә болай дип әйтә торган булган: «Расүлуллаһның хатыннарыннан Хәдичәдән көнләшкәнем кадәр беркемнән дә шулкадәр көнләшмәдем. Аның кебекне күрмәдем. Ул Расүлуллаһ өчен бик мөһим иде. Һәрвакыт корбан чалгач та, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм әүвәл Хәдичәнең якыннары һәм дусларына өлеш чыгарыр иде» (имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан).

Әйткәнебезчә, Гайшә радыяллаһу ганһә ирен бик көнләгән һәм бервакыт бу гамәле белән аны үпкәләткән. Кызы өчен борчылып, Өмме Руман радыяллаһу ганһә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килеп: «Ий, Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм, кызым Гайшә булган хәлләр өчен бик борчыла. Гафу ит аны», – дип әйткән.

Өмме Руман радыяллаһу ганһәнең улы – Габдерахман бине Әбү Бәкер ислам динен кабул итәргә ашыкмаган. Әлбәттә, ана йөрәге бу хәлгә бик кайгырган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән корәешләләр арасында Ходәйбия килешүе төзелгән елны гына Габдрахман ислам динен кабул итеп, мөселман булган. Шушы 628 елда Габдерахманның әнисе Өмме Руман радыяллаһу ганһә вафат булган.

Өмме Руман радыяллаһу ганһәнең үлеменә кызы Гайшәгә бәйле вакыйга да сәбәп булган. Гайшә радыяллаһу ганһә хакында ялган сүзләр таралгач, әнисе Өмме Руман бик кайгырган. Бер ай дәвамында ул үзендә көч табып, кызына нык лы терәк булган. Бик авыр булса да, ул берәүгә дә начар сүз белән җавап кайтармаган. Кешеләр арасында таралган сүзләрне дә кызына сөйләмәгән, аны саклаган. Кызын тынычландырып: «Кызым, борчылма! Ант итәм, кешеләр һәрвакытта да ире өзелеп ярата торган һәм көндәшләре булган чибәр хатын турында гайбәт сөйләячәкләр», – дип әйткән (имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан).

## Вафаты һәм җәннәт белән шатландырылуы

Аллаһы Тәгалә кызы Гайшә радыяллаһу ганһәне аклаган аять иңдергәннән соң озак та үтми, һиҗри белән алтынчы елда Өмме Руман радыяллаһу ганһә вафат булган.

Өмме Руман радыяллаһу ганһәнең гәүдәсен кабергә салганда Аллаһының Расүле болай дип әйткән: «Зур кара күзле хур кызларын күрәсе килгән кеше Өмме Руман радыяллаһу ганһәгә карасын». Шул рәвешле, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Өмме Руман радыяллаһу ганһәнең җәннәттә булачагы хакында хәбәр биргән.

■ Сәхифәне
**Лилия ХӘЛӘФЕТДИНОВА** әзерләде




Фото: shutterstock.com

# Кояшлы дала кызы

*(Повестьтән өзек)*

Сания тәрәзә аша урамны күзәтә. Җир өстенә Яңа елның назланып кына, гыйнвар ае кары ява. Капкадан хат ташучы Ләвия кергәнен күреп, ишек ачты.

– Сания апа! Син яратып укый торган «Азбука Корана» белән «Тайна здоровья» газеталарын китердем, – дип, янына утырып, хәлен сорашты.

– Аллаһка хисапсыз шөкер! Сиксән бишенче кышымны каршылыйм, – диде.

Хат ташучы, аның төз гәүдәсенә, ачык зиһененә сокланып карады.

– Синең яшеңдә мин дә матур килеш калсам иде. Тик бу бәхет, бар кешегә дә тими шул, – диде, урта яшьләрдәге Ләвия. – Серен әйтеп калдыр әле миңа, Сания апа.

– Минем кебек гади итеп яшәргә кирәк. Әз малың, күп куанычың булсын, диләр. Саулыгын сакларга, һәркем үзе өйрәнергә тиеш. Сәламәтлегеңә карата игътибарсыз булырга ярамый. Кырык елдан артык, яман чир белән көрәшеп яшәдем, – дигәч, хат ташучы уйчанланып калды, аннары: – Син, Сания апа, заманның алдынгы карашлы хатын-кызы! Өстәлеңдә – ноутбук, айпат! Оныкларың да үзеңә охшаган – башлы! Айрат оныгыңны Мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры итеп куйганнарын күрдеңме телевизордан? Һәр газетада язып чыктылар. Безнең Баулы районы кешесенең министр булуы шатлык бит, – диде, балалар кебек сөенеп.

– Башкалар өчен куана белгәч, әйбәт кеше син, Ләвия, күңелеңә яхшы орлык салынган, – дип әйтеп бетерүгә, өй ишеген шакыдылар.

– Бу вакытта укучыларым килеп хәлемне белеп китәләр. Йә Гөлназ Хәннанова, йә Алсу Гыйззәтуллина, йә Зөлфирә Нуриева. Кайсысы икән? – дип, сөйләнә-сөйләнә, ишекне ачып җибәрсә, каршында – кызы, оныклары Айрат, Артур, Азат гаиләсе басып тора.

– Әнием, җаным, сөенечеңнән егылып китә күрмә, – дип, Венера иңеннән тотты.

– Егылмыйм, кызым, әйдәгез, балалар узыгыз!

...Сания оныклары уртасында басып калды, һәрберсе дәү әниләрен сагынып килүләрен үзенчә җиткерде: кайсы кочаклады, кайсы битеннән үпте, кайсы кулын кысты.

Зал ягына кереп, тезелешеп утырышкач:

– Йә, кайсыгыздан башлыйбыз? Сөйләгез миңа... – диде дәү әниләре – Айрат улым, зур вазифа тапшырдылар сиңа. Әлмәт районы башлыгы булып эшләгәндә, халык яратты үзеңне. Бу эшеңдә дә халыкка якын булсаң, зур эшләрне тизрәк башкарырсың, – диде.

Айрат, дәү әнисенең йөзенә карап, яратып елмайды.

– Авылда яшәүчеләргә дә шәһәр кешеләре кебек үк, бер үк төрле уңайлыклар тудырырга вакыт җитте, дәү әни. Ни кызганыч, әле республикабызның егерме ике авылында мобиль элемтәдән файдалана алмыйлар. Эш юнәлеше билгеләнгән: команда яхшы, булдырырбыз! – дигән җавабын ишеткәч, карашын Артурга юнәлдерде.



– Йә, улым, синең эшләрең кай тирәдә? Яшүсмер чагыңнан аш-су тирәсендә кайнашырга ярата идең. Такташ әйтмешли, балачак шөгылең үзеңә ияреп йөрде. «АРТВИКА-Хлеб» пекарнясы турындагы яңалыкларны интернет челтәреннән укып торам. Исемен дә, Артур белән Викториянең баштагы өч хәрефен кушып куйгансыз. Ниһаять, халык чүпрәсез, ясалма витаминнар кушылмаган азыкка игътибар бирә башлады. Үз саулыгына битараф булмаган культуралы даирәгә хезмәт күрсәтәсең, улым, булдырасыз! – дигәч, Артурның йөзенә кояш нуры иңгәндәй яктырды.

– Ну, дәү әни, беләсең син, барысын да укып барасың икән. Әйе, пекарня елдан-ел киңәя бара. Икмәк-булканы гына түгел, кондитер әйберләр ассортиментын да гел төрләндереп торабыз. Кухня ягында киленнәрең өстәл әзерли, безнең продукцияне ашап карагач, үз фикереңне тагын әйтерсең, дәү әни.

Абыйларының дәү әниләре белән рәхәтләнеп сөйләшкәнен тыңлап утырган Азат:

– Чират миңа җиттеме, дәү әнием, – дип, көлемсерәп куйды.

– Син улым – 21нче гасыр медигы! Безнең заманда робот дигән сүз дә юк иде. Ә син шушы эш белән Япониягә кадәр барып җиттең. Йә, сөйлә әйдә, японнарда тормышлар ничек?

– Гади итеп кенә әйтсәм, Япониядә роботлар киң кулланыла. Минем эшем – медицинада кулланыла торган робот инструментлар ясау. Мәсәлән, грипп вирусын авыл районнары хастаханәләре лабораториясендә әле дә кан анализы белән ачыклыйлар. Япониядә, күп еллардан бирле, борын куышлыгындагы лайла аша гына ачыклана. Кайсы гына тармагын карасаң да алга киткән ил, – дип әйтеп бетерүгә, кухня ягында Азатның хатыны Лия, Япониядә яши башлагач, үзләре белән булган вакыйганы сөйләргә керешә.

– Кибеттә йөрибез, бала арбасында телефоным белән акчам салынган сумкам онытылып калганы исемә төште. Йөгереп бардым арбаны калдырган урынга. Сумкамны кулыма алгач, шатлыгымнан нишләргә белмәгәнем йөземә чыккандыр, күрәсең. Кибет хезмәткәрләре миңа гаҗәпләнеп карап торды да, кайсы ил гражданы булуым белән кызыксынды. Аннары, күземә туп-туры карап әйтте бер япон кызы: «Безнең илдә кеше әйберенә кагылмыйлар. Караклык юк!» – диде. Шул вакыйганы исемә төшерсәм, хәзер дә уңайсыз булып китә. Япон халкы, дөрестән дә, югары культурага ия.

Барысы да бу вакыйгага карата үз фикерен әйтте. «Безнең илдә дә халык карак түгел, аерым кешеләр генә үзеңнеке булмаган әйберне үзләштерергә ярамаганлыгын белмиләр. Аларга, әти-әнисе, әби-бабайсы, туганнары тарафыннан кеше әйберенә рөхсәтсез кагылырга ярамаганлыгы, урлауның җинаять икәне аңлатылмаган, тәрбия бирелмәгән».

– Сезгә ул яктан тәрбия көчле бирелде. Безнең нәсел, гомер-гомергә, үз тырышлыгына таянып көн иткән. Безнең канда, караклык яки кеше хакын ашау юк. Үз заманы өчен әби-бабайлар, әти-әни дә белемле булган. Яздырып алдыра торган газеталарымның бер битен дә калдырмыйча укыйм. «Азбука Корана»да бик акыллы фикер укыдым: «Кеше күңеле – су тутырган савыт кебек. Әгәр дә суын гел яңартып, алыштырып тормасаң, исләнә башлый. Күңелеңнең чиста су кебек булуын теләсәң, аны белем белән яңартып тор!» Нинди үтемле чагыштыру! – диде Сания.

– Дәү әниегез мине дә уздырып җибәрә хәзер. Кайда, нинди конкурс игълан ителүен, карап кына тора, – диде Венера. – Мәскәү Диния назәрәте игълан иткән конкурсларда тугыз ел рәттән катнашты. Ел саен Грамота алып тора. Былтыр Әлмәт районы Үзәк мәчетендә «Аллаһның туксан тугыз исемен яттан сөйләүчеләр» бәйгесендә катнашып, үз яшендәге әбиләр арасында беренче урынны алып кайтты. Йә әни, үзеңнең иҗат җимешләреңнең берәрсен укып күрсәт әле оныкларыңа.

Кызының сүзе, әнисенең йөрәгенә сары май булып ятты. Калын дәфтәрләре арасыннан конкурска катнашырга язган шигырен укый башлады.

*Бер Аллага табынып,*
*Укыймын көндә намаз.*
*Раббыма сыенып, йөрәгемне ачып,*
*Гөнаһларны ярлыка дип,*
*Маңгайны җиргә куеп.*
*Күздән тама кайнар яшь,*
*Сулкылдап тибә йөрәк.*
*Тыныч илдә яшәү үзе,*
*Аллаһыдан зур бүләк.*
*Якты кояш, айлы төн,*
*Зәңгәр күктә йолдызлар.*
*Якты күлдә балык йөзә,*
*Болында үсә чәчәкләр.*
*Талга кунып сайрый кошчык,*
*Ә мин догамны кылам,*
*Аллаһ белән күрешеп,*
*Йөрәк серемне чишеп.*
*Укыйм Коръән –*
*Аллаһның тере сүзен.*
*Сөекле пәйгамбәребез*
*Мөхәммәтне маяк итеп,*
*Сайлаган Үзе безгә.*
*Биш тапкыр Раббым белән, очрашулар - зур бәхет, Җәннәткә бару юллары, булса иде хәерле.*
*Намаз укыган саен,*
*Якынаям Аллаһка,*
*Үзем укыйм, үзем елыйм,*
*Күңелем сафлыгын тоям.*

Дәү әниләренең иҗат җимешен, барысы да тын калып тыңлады. Айрат шунда:

– Безнең шагыйрәбез син! – дип, кочаклап алды. – Шушы йортта үстем! Рәхмәт сиңа, кадерле дәү әнием. Син барыбызны да белем белән тукландырып тордың, дөрес юл күрсәттең. Бүген без уңышларга ирешкәнбез икән, ул – синең дә уңышың, – диде.

...Кухня ягыннан тәмле исләр таралды. Барысы да өстәл янына утырышкач, оныкларын ияртеп, Ринат кияү килде.

– Гаилә түгәрәкләнде, – диде Азат.

– Олег белән Александр гаиләсе генә җитми, – дип әйтеп куйды Венера.

Сания икесенең дә Яңа ел елларында кайтабыз, дип шалтыратканнарын әйтте. Олегның хәрби хезмәт срогын тутыргач, Казанга кайтып, төзелеш фирмасына эшкә урнашуына барысы да куануларын белдерделәр. Айрат, Александрның да киләсе елга хәрби контракт срогы тулганын, армия офицерларына бирелә торган ярдәм белән Казаннан фатир алуын әйтеп, дәү әнисен сөендерде.

■ Гөлсинә ГАЛИМУЛЛИНА

**Хөрмәтле радиотыңлаучылар!**

«Азан» радиосын azan.fm сайтында яки «Азан» радиосы рәсми кушымталары аша тыңлагыз. Моның өчен түбәндәге QR-код аша үтегез яки App Store (iPhone өчен) һәм Google Play Market (Android өчен) платформаларыннан «Азан радиосы» кушымтасын йөкләп алыгыз.

**QR – кодлар:**

Android өчен:

iPhone өчен:

**Сайт:** azan.fm
**Инстаграм:** azan.fm
**Вконтакте:** azanfm
**Телеграм-канал:** azanfm

**Почта:** radio@azan.fm
**Тел.:** 8 (843) 598-09-43

**ДҮШӘМБЕ, СИШӘМБЕ, ЧӘРШӘМБЕ, ПӘНҖЕШӘМБЕ**

0:00 Коръәни Кәрим – 0+
6:05 Коръән тәфсире – 12+
6:25 Көндәлек догалар – 6+
6:30 Тынычлык тәгълимате –12+
7:05 Таян Аллаһка – 6+
7:20 Хәзрәткә сорау –12+
7:30 Иман тәме –12+
7:50 Миллият сүзлеге – 6+
7:55 Гыйбрәтле кыйссалар – 6+
8:05 Бәхет тулы йорт –12+
8:30 Күңелдән күңелгә –12+
8:50 Шәхесләргә шәрехләр – 6+
9:00 Рухи хәзинә – 6+
9:15 Гыйбадәте Исламия – 6+
9:30 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) –12+
9:40 Әбү Хәнифә (р.г.) –12+
10:40 Миллият сүзлеге – 6+
10:45 Көндәлек догалар – 6+
10:50 Һәр яхшы сүз – сәдака – 6+
11:00 40 хәдис – 6+
11:20 Аллаһның 99 исеме – 6+
11:30 Мәчетләребез тарихы – 6+
11:40 101 вәгазь –12+
12:00 Өйләгә азан – 0+
12:10 Гыйбадәте Исламия – 6+
12:25 Миллият сүзлеге – 6+
12:30 Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә –12+
14:00 Гыйбадәттә сәгадәт –12+
14:10 Әхлак баскычлары – 6+
14:30 Пәйгамбәрләр тарихы –12+
14:45 Сөннәт юлы –12+
15:05 Коръән тәфсире –12+
15:25 Көндәлек догалар – 6+
15:45 Бәхет тулы йорт –12+
16:05 Миллият сүзлеге – 6+
16:10 Гыйбрәтле кыйссалар – 6+
16:20 101 вәгазь –12+
16:40 Күңелдән күңелгә –12+
17:00 Шәхесләргә шәрехләр – 6+
17:10 Гыйбадәте Исламия – 6+
17:30 Һәр яхшы сүз – сәдака – 6+
17:40 40 хәдис – 6+
19:30 Әдәбият күрке әдәп – 6+
19:45 Миллият сүзлеге – 6+
20:00 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.)–12+
20:20 Һәр яхшы сүз – сәдака – 6+
20:30 Нәниләргә нәсыйхәт – 6+
20:35 Пәйгамбәрләр тарихы –12+
20:50 Көндәлек догалар – 6+
21:10 Мәчетләребез тарихы – 6+
21:30 Әбү Хәнифә (р.г.) –12+
21:50 Хәзрәткә сорау –12+
22:00 Гыйбадәттә сәгадәт –12+
22:10 Әхлак баскычлары – 6+
22:37 Миллият сүзлеге – 6+
22:45 Аллаһның 99 исеме – 6+
23:00 Коръәни Кәрим – 0+

**ҖОМГА**

0:00 Коръәни Кәрим – 0+
6:00 Җомга тәбриге –12+
6:05 Коръән тәфсире –12+
6:25 Көндәлек догалар – 6+
6:30 Тынычлык тәгълимате –12+
7:05 Таян Аллаһка – 6+
7:20 Хәзрәткә сорау –12+
7:30 Иман тәме –12+
7:50 Миллият сүзлеге – 6+
7:55 Гыйбрәтле кыйссалар – 6+
8:05 Бәхет тулы йорт –12+
8:25 Җомга тәбриге –12+
8:30 Күңелдән күңелгә –12+
8:50 Шәхесләргә шәрехләр – 6+
9:00 Рухи хәзинә – 6+
9:15 Гыйбадәте Исламия – 6+
9:30 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) – 12+
9:40 Әбү Хәнифә (р.г.) – 12+
10:00 Җомга тәбриге – 12+
10:40 Миллият сүзлеге – 6+
10:45 Көндәлек догалар – 6+
10:50 Һәр яхшы сүз – сәдака – 6+
11:00 40 хәдис – 6+
11:20 Аллаһның 99 исеме – 6+
11:30 Мәчетләребез тарихы – 6+
11:40 101 вәгазь – 12+
12:00 Өйләгә азан – 0+
12:10 Гыйбадәте Исламия – 6+
12:25 Миллият сүзлеге – 6+
12:30 Кәлам Шәриф. Мәгънәви тәрҗемә – 12+
14:00 Гыйбадәттә сәгадәт – 12+
14:10 Әхлак баскычлары – 6+
14:30 Пәйгамбәрләр тарихы – 12+
14:45 Сөннәт юлы – 12+
15:00 Җомга тәбриге – 12+
15:05 Коръән тәфсире – 12+
15:25 Көндәлек догалар – 6+
15:45 Бәхет тулы йорт – 12+
16:05 Миллият сүзлеге – 6+
16:10 Гыйбрәтле кыйссалар – 6+
16:20 101 вәгазь – 12+
16:40 Күңелдән күңелгә – 12+
17:00 Шәхесләргә шәрехләр – 6+
17:10 Гыйбадәте Исламия – 6+
17:30 Һәр яхшы сүз – сәдака – 6+
17:40 40 хәдис – 6+
19:30 Әдәбият күрке әдәп – 12+
19:45 Миллият сүзлеге – 6+
20:00 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) – 12+
20:20 Һәр яхшы сүз – сәдака – 6+
20:30 Нәниләргә нәсыйхәт – 6+
20:35 Пәйгамбәрләр тарихы – 12+
20:50 Көндәлек догалар – 6+
21:10 Мәчетләребез тарихы – 6+
21:30 Әбү Хәнифә (р.г.) – 12+
21:50 Хәзрәткә сорау – 12+
22:00 Гыйбадәттә сәгадәт – 12+
22:10 Әхлак баскычлары – 6+
22:37 Миллият сүзлеге – 6+
22:45 Аллаһның 99 исеме – 6+
23:00 Коръәни Кәрим – 0+

**ШИМБӘ, ЯКШӘМБЕ**

0:00 Коръәни Кәрим – 0+
6:05 Коръән тәфсире – 12+
6:25 Көндәлек догалар – 6+
6:30 Тынычлык тәгълимате – 12+
7:05 Таян Аллаһка – 6+
7:20 Хәзрәткә сорау – 12+
7:30 Иман тәме –12+
7:50 Миллият сүзлеге –6+
7:55 Гыйбрәтле кыйссалар –6+
8:05 Бәхет тулы йорт –12+
8:30 Күңелдән күңелгә –12+
8:50 Шәхесләргә шәрехләр –6+
9:00 Рухи хәзинә –6+
9:15 Гыйбадәте Исламия –6+
9:30 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) –12+
9:40 Әбү Хәнифә (р.г.) –12+
10:40 Миллият сүзлеге –6+
10:45 Көндәлек догалар –6+
10:50 Һәр яхшы сүз – сәдака –6+
11:00 40 хәдис –6+
11:20 Аллаһның 99 исеме –6+
11:30 Мәчетләребез тарихы –6+
11:40 101 вәгазь –12+
12:00 Өйләгә азан –0+
12:10 Гыйбадәте Исламия –6+
12:25 Миллият сүзлеге –6+
12:30 Кәлам Шәриф. Тәрҗемә –12+
14:00 Гыйбадәттә сәгадәт – 6+
14:10 Әхлак баскычлары – 6+
14:30 Пәйгамбәрләр тарихы –12+
14:45 Сөннәт юлы –12+
15:05 Коръән тәфсире –12+
15:25 Көндәлек догалар –6+
15:45 Бәхет тулы йорт –12+
16:05 Миллият сүзлеге –6+
16:10 Гыйбрәтле кыйссалар –6+
16:20 101 вәгазь –12+
16:40 Күңелдән күңелгә –12+
17:00 Шәхесләргә шәрехләр – 6+
17:10 Гыйбадәте Исламия –6+
17:30 Һәр яхшы сүз – сәдака –6+
17:40 40 хәдис –6+
19:30 Әдәбият күрке әдәп –12+
19:45 Миллият сүзлеге –6+
20:00 Хәяте Мөхәммәд (с.г.в.) –12+
20:20 Һәр яхшы сүз – сәдака –6+
20:30 Нәниләргә нәсыйхәт –6+
20:35 Пәйгамбәрләр тарихы –12+
20:50 Көндәлек догалар –6+
21:10 Мәчетләребез тарихы –6+
21:30 Әбү Хәнифә (р.г.) –12+
21:50 Хәзрәткә сорау –12+
22:00 Гыйбадәттә сәгадәт –12+
22.10 Әхлак баскычлары –6+
22:37 Миллият сүзлеге –6+
22:45 Аллаһның 99 исеме –6+
23:00 Коръәни Кәрим –0+

*Тапшырулар арасында эфирда нәшидләр һәм мөнәҗәтләр яңгырый*

# Казан өчен гыйнвар аена намаз вакытлары

| Көн | Көн исеме | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Зәвәл | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы/ ифтар | Ясту намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | | |
| 01.01.2022 | Шим | 05:53 | 06:43 | 08:13 | 11:46 | 12:00 | 13:33 | 15:21 | 17:18 |
| 02.01.2022 | Якш | 05:53 | 06:42 | 08:12 | 11:47 | 12:00 | 13:35 | 15:22 | 17:19 |
| 03.01.2022 | Дүш | 05:53 | 06:42 | 08:12 | 11:47 | 12:00 | 13:36 | 15:23 | 17:20 |
| 04.01.2022 | Сиш | 05:52 | 06:42 | 08:12 | 11:48 | 12:00 | 13:37 | 15:24 | 17:21 |
| 05.01.2022 | Чәрш | 05:52 | 06:41 | 08:11 | 11:48 | 12:00 | 13:38 | 15:26 | 17:23 |
| 06.01.2022 | Пәнҗ | 05:52 | 06:41 | 08:11 | 11:49 | 12:00 | 13:40 | 15:27 | 17:24 |
| 07.01.2022 | Җом | 05:52 | 06:40 | 08:10 | 11:49 | 12:00 | 13:41 | 15:29 | 17:25 |
| 08.01.2022 | Шим | 05:51 | 06:39 | 08:09 | 11:50 | 12:00 | 13:42 | 15:30 | 17:26 |
| 09.01.2022 | Якш | 05:51 | 06:39 | 08:09 | 11:50 | 12:00 | 13:44 | 15:32 | 17:27 |
| 10.01.2022 | Дүш | 05:51 | 06:38 | 08:08 | 11:50 | 12:00 | 13:45 | 15:34 | 17:29 |
| 11.01.2022 | Сиш | 05:50 | 06:37 | 08:07 | 11:51 | 12:00 | 13:47 | 15:35 | 17:30 |
| 12.01.2022 | Чәрш | 05:50 | 06:36 | 08:06 | 11:51 | 12:00 | 13:48 | 15:37 | 17:31 |
| 13.01.2022 | Пәнҗ | 05:49 | 06:35 | 08:05 | 11:52 | 12:00 | 13:50 | 15:39 | 17:33 |
| 14.01.2022 | Җом | 05:48 | 06:34 | 08:04 | 11:52 | 12:00 | 13:52 | 15:40 | 17:34 |
| 15.01.2022 | Шим | 05:48 | 06:33 | 08:03 | 11:52 | 12:00 | 13:53 | 15:42 | 17:36 |
| 16.01.2022 | Якш | 05:47 | 06:32 | 08:02 | 11:53 | 12:00 | 13:55 | 15:44 | 17:37 |
| 17.01.2022 | Дүш | 05:46 | 06:31 | 08:01 | 11:53 | 12:00 | 13:57 | 15:46 | 17:39 |
| 18.01.2022 | Сиш | 05:45 | 06:29 | 07:59 | 11:53 | 12:00 | 13:58 | 15:48 | 17:40 |
| 19.01.2022 | Чәрш | 05:44 | 06:28 | 07:58 | 11:54 | 12:00 | 14:00 | 15:50 | 17:42 |
| 20.01.2022 | Пәнҗ | 05:43 | 06:27 | 07:57 | 11:54 | 12:00 | 14:02 | 15:52 | 17:43 |
| 21.01.2022 | Җом | 05:42 | 06:25 | 07:55 | 11:54 | 12:00 | 14:04 | 15:54 | 17:45 |
| 22.01.2022 | Шим | 05:41 | 06:24 | 07:54 | 11:55 | 12:00 | 14:06 | 15:56 | 17:47 |
| 23.01.2022 | Якш | 05:40 | 06:22 | 07:52 | 11:55 | 12:00 | 14:08 | 15:58 | 17:48 |
| 24.01.2022 | Дүш | 05:39 | 06:21 | 07:51 | 11:55 | 12:00 | 14:09 | 16:00 | 17:50 |
| 25.01.2022 | Сиш | 05:38 | 06:19 | 07:49 | 11:55 | 12:00 | 14:11 | 16:02 | 17:52 |
| 26.01.2022 | Чәрш | 05:37 | 06:18 | 07:48 | 11:55 | 12:00 | 14:13 | 16:04 | 17:53 |
| 27.01.2022 | Пәнҗ | 05:36 | 06:16 | 07:46 | 11:56 | 12:00 | 14:15 | 16:06 | 17:55 |
| 28.01.2022 | Җом | 05:34 | 06:14 | 07:44 | 11:56 | 12:00 | 14:17 | 16:08 | 17:57 |
| 29.01.2022 | Шим | 05:33 | 06:13 | 07:43 | 11:56 | 12:00 | 14:19 | 16:10 | 17:59 |
| 30.01.2022 | Якш | 05:31 | 06:11 | 07:41 | 11:56 | 12:00 | 14:21 | 16:12 | 18:00 |
| 31.01.2022 | Дүш | 05:30 | 06:09 | 07:39 | 11:56 | 12.00 | 14:23 | 16:15 | 18:02 |

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
*Декабр саны, №12 (317)*

Баш мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Мөхәррирләр: **Хәләфетдинова Л.Г.**, **Юлдашева А.И.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сабирова Ф.И.**

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**

«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;
ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБАРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2542
Газетага ярты елга язылу бәясе – 140 сум 40 тиен. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 28 нче декабрьдә таратыла.
График буенча бу санга 27 нче декабрь көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.